ФИРДҮС ФӘТХЕЛИСЛАМ

# УЙЛАРНЫҢ ЙӨРТИК ИЗГЕСЕН

دروس في الاسلام

ФИРДҮС ФӘТХЕЛИСЛАМ

# УЙЛАРНЫҢ ЙӨРТИК ИЗГЕСЕН

КАЗАН
«МАТБУГАТ ЙОРТЫ» НӘШРИЯТЫ
2004

ББК 84 Тат 7-5
Ф27

**Фәтхелислам Ф.**

Ф27 Уйларның йөртик изгесен. — Казан: «Матбугат йорты», 2004. — 80 бит.

Бу китаптагы әсәрләрне фәлсәфи-нәфис хикәяләр дип атарга мөмкин. Бер караганда аларда авторның бүгенге уйлары, фикерләре, фәлсәфәсе, дөньяга карашы ачыктан-ачык сөйләп бирелә, икенче яктан караганда алардагы әдәби нәфис тел, сюжет һәм кызыклы сөйләм алымы коеп куйган әдәби дәрәҗәдә.

ISBN 5-94259-131-8

© Фәтхелисламов Ф., 2004

*Милләтнең тәрәккыйсенә вә башка милләтләрнең аяклары астында тапталмавына кирәкле нәрсәнең һәммәсе дә саваплы вә хәерле бер эштер.*

*Г. Тукай*

## МИЛЛӘТПӘРВАР ФИРДҮС

Фирдүс Фәтхелисламны шәхес буларак, кызыклы әңгәмәдәш, шактый гына дәрәҗәдә фикердәш, туган халкыбыз, аның иң ерак тарихыннан алып бүгенге көндәге мәшәкатьләре турында тирән уйланучы, җәмгыять тормышының һәр мәсьәләсендә үзе нык ышанган фәлсәфи фикере булган замандашым буларак аның фәлсәфи-публицистик һәм әдәби әсәрләре белән танышканча ук белә идем. Безнең көндәлек тормышта тыз-быз чаба торган сукмакларыбыз еш кына кисешеп тора һәм без һәр очрашуда тарих, заман, дин, милләт һәм халыклар язмышы турында икебезне бердәй кызыксындырган мәсьәләләр турында гәп корабыз. Фирдүснең әлеге өлкәләрдә үзенә генә хас булган, Совет чорындагы һәм бүгенге стандартларга сыймый торган үз фикере, үз иманы, үз шәрехләве бар. Миңа аеруча шунсы ошый, ул бүгенге җәмгыять тормышында актуаль булган бер генә сәяси мәсьәләдә дә чиктән-чиккә ташланмый, бер генә фикерне алга сөреп киреләнми, ә һәр мәсьәләдә тарихи мантыйк, тормыш агымындагы реаль күренешләргә нигезләнеп фикер йөртә. Әңгәмәдә, фикер алышуда, нәрсәнедер раслаганда яки кире какканда ул бернинди фетишларга да таянмый, инануларында чалуламый.

Фирдүснең әнә шундый сыйфатлары мине үзенә җәлеп итте һәм без, моңарчы бернинди уртаклыкларыбыз да булмаган ике замандаш, бер-беребезне яхшы аңлаучы әңгәмәдәшләр булып киттек.

Әйткәнемчә, болар барысы да очраклы очрашуларыбыз аркасында гына булды...

Менә бүген минем алда Фирдүс Фәтхелисламның әдәби әсәрләре, китаплары... Миңа, туган әдәбиятыбыз кырында инде кырык елдан артык үз кишәрлегемне сукалаучы бер абзыйга, бүгенге әдәбиятыбызга аяк баскан яңа исемнәр, аларның әсәрләре гаять кызыклы. Кем килә, аның әдәби җегәре ниндирәк, телне, сүз сәнгатен, язма нәфислекне тою, шуны кәгазьгә иңдерү куәте бармы, гомумән мең еллык тарихы булган татар әдәбиятының югары дәрәҗәсен кимсетмәслек көч бармы аның әсәрләрендә? Мин әдәбиятка килүче һәр яңа исемне әнә шундый сораулар яссылыгына куеп карыйм.

Фирдүс Фәтхелисламның дөнья күргән ике китабы бар. 1997 елда Татартсан китап нәшриятында аның балалар өчен “Кояш халкы язмышы” дигән экият-риваяте басылып чыккан. 2001 елда Казандагы “Матбугат йорты” нәшриятында “Мәхәббәт әкәмәте” дигән хикәяләр тупланмасы дөнья күргән. Боларга өстәмә итеп бүген укучы кулындагы “Уйларның йөртик изгесен” дигән китапның кулъязмасы да минем язу өстәлендә. Өч китап иҗат итү инде ул әдипкә карата җитди игътибар сорый. Кызганычка каршы (ә бәлки бәхеткә каршыдыр) күпләр бер китап чыгара да туктап кала. Фирдүс исә әдәби иҗат эшенә ныгытып тотынган, ул бу эшне эзлекле рәвештә дәвам итә.

Язучы Фирдүс минем кызыклы әңгәмәдәшем Фирдүс кебек үк татар халкының борынгыдан алып бүгенге көнгәчә булган тормышының төрле яклары турында кызыксынучы, кайгыртучы чын милләтпәрвар кеше. Әмма язучы Фирдүс әңгәмәдәш Фирдүскә караганда гаять бай хисле, мәхәббәттә дөрләп янучы, туган-тумачаларын, авылдашларын, классташларын, туган авылының һәр үләнен, чәчәген, урман-суын, тау-калкулыгын, бигрәк тә гореф-гадәтләрен, кызыклы шәхесләрен яратучы, аларны өзелеп сагынучы, халкыбызның ул гына белгән гореф-гадәтләре, милли фәлсәфә, татарның үзенчәлеге белән горурланучы чын патриот ир-егет, ходавәндә...

Фирдүснең әсәрләре фәлсәфи яктан безнең хисләрне кирегә, өметсезлеккә, сүнүгә таба алып бармый, ә алга, лаеклы киләчәккә дәшә. Гәрчә аның әсәрләрендә тәнкыйди башлангыч та, мыскыллы көлү дә, хәтта турыдан-туры килешмәүчәнлек тә бар. Әмма алар барысы да безне, гомум милләт буларак үсә барырга, югалмаска, вакланмаска дәшә.

Мине Фирдүснең әдәбиятта төрле жанрларда эшләве дә куандыра. Тарихыбыз, диннәр, халкыбызның гореф-гадәтләре, холкына багышланган гаять катлаулы мәсьәләләр турындагы риваятьләргә нигезләнгән “Кояш халкы язмышы” дигән китабын ул балаларга багышлаган. Әмма китап олылар өчен дә бик гыйбрәтле. Ә инде анда сүрәтләнгән вакыйгалар, әдәби геройларның бала күңеленә сеңеп калуы халкыбызның киләчәгенә йөз тота, тарихыбызның дәвамчылылыгы турында кайгырта.

“Мәхәббәт әкәмәте” киресенчә, бүген яшәп яткан татар кешесенең яшәү рәвеше, мәхәббәте, самими хисләре хакында. Ләкин андагы һәр хикәя татар халкына гына хас булган холык-фигыль, хис, үзара мөнәсәбәтләр хакында. Ахыр килеп бу хикәяләр

татар менталитетының борынгысын бүгенге белән бәйли, әлеге дәвамчылыкны күздә тота.

Укучы кулындагы бу китап та нигездә Фирдүснең төп милләтпәрварлык магистрален дәвам итә. Эчтәлек, фәлсәфә, әйтәсе килгән фикер ягыннан әдип бу китапта да үзенә тугрылыклы булып кала. Әмма әдәби жанр ягыннан бу китапта Фирдүс бөтенләй яңа яктан ачылып китә. Мин бу китаптагы әсәрләрне публицистик фәлсәфи-нәфис хикәяләр дип атар идем. Бер караганда аларда авторның бүгенге уйлары, фикерләре, фәлсәфәсе, дөньяга карашы ачыктан-ачык сөйләп бирелә, икенче яктан карaганда алардагы әдәби нәфис тел, сюжет һәм кызыклы сөйләм алымы коеп куйган әдәби дәрәҗәдә. Мондый әсәрләр безнең бүгенге матбугатыбыз, әдәбиятыбыз өчен бик табигый яңгырый. Мин бу китап укучы тарафыннан яратып кабул ителер дип ышанам һәм аңа татар булган һәр кеше күңеленә хәерле юл телим.

*Гәрәй РӘХИМ,*
*Татарстанның Г.Тукай исемендәге*
*Дәүләт премиясе лауреаты*

# ГЫЙБРӘТ БУЛСЫН

*(сүз башы)*

Тормыш бик кызык нәрсә инде ул. Егерме яшькә кадәр кеше ата-анасы тәрбиясендә рәхәт, күңелле яши. Егерме яшьтән соң, ат кебек дөнья нужасын сөйри, күп эшли. Кырык яшьтән соң эт гомеренә керә: аның балалары үскән була, ул аларга “өреп” утыра. Ник “өрә”? Чөнки үкенә, үз тормышында күп хата җибәреп, менә дигән шәп форсатларны ычкындыруына үкенә, балаларым да алай эшләмәсен иде дип, аларга үгет-нәсихәт бирә. Хәятебездә күп нәрсә кабатлана бит ул, ялгышлар да кабатлана, үкенечләр дә.

— Тукта әле, мин ясаган ялгышларны ни өчен минем улым да, оныкларым да ясарга тиеш? — дип уйлый кеше һәм “өрә” дә “өрә”. Әмма үгет-нәсихәттән адәм баласы әллә кайчан туеп беткән инде. Акыл өйрәтеп торучыны элек тә яратмаганнар, хәзер дә тыңламыйлар. Нишләргә? Хәзерге яшьләргә кырын карап та, ачуланып та тәэсир итеп булмый. Мин үзем озын-озак уйладым да, тормыш тәҗрибәмне хатлар формасында, мөмкин булган кадәр кызык итеп, мәзәген-мәкален кыстырып тасвирларга булдым. Бу хикәяләр гайбәт түгел, гыйбрәт булсын, яшьләрне хәвеф-хәтәрдән сакласын иде.

Менә шундый изге уй-ният белән ике-өч мәкалә язгач, мин туктап калдым. Яшьләргә алай эшләмә, болай эшлә дип акыл бирү генә җитми. Аларга халкыбызның тарихы, аның казанышлары һәм югалтулары турында да белем кирәк. Безнең үткәнебез бик буталчык итеп тасвирланган, еш кына бер үк вакыйгаларга капма-каршы аңлатма бирелә. Кайбер нәрсәне төшенер өчен айлар буе эзләнәсең, күп вакыт һәм акыл көче сарыф итәсең. Нигә бу эшне кабат башкарырга? Шуңа күрә мин бу җыентыкта элек язылып, төрле гәҗит-журналларда дөнья күргән мәкаләләрне дә урнаштырырга булдым. Без белгәнне, без аңлаганны үзләштереп, яшьләр уй-фикерне үстерсеннәр, яңа гасырның мәсьәләләрен чишсеннәр иде.

# ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУЧЫСЫ

Укытучы. Һәркем бу сүзне тирән ихтирамын белдереп әйтә. Адәм баласы үзен укырга һәм язарга, тормышның ямен күрергә өйрәткән газиз укытучысына мең рәхмәтле.

Роза Сахип кызы Мәрдәнова шундый хөрмәткә лаеклылардан. Ул зур укыту тәҗрибәсенә ия, инде күп еллар М.Н.Вахитов исемендәге Буа урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыта. Үзен балалар бик ярата.

Р.Мәрдәнова — ихлас күңеленнән үз эшенә бирелгән белгеч. Һәр дәрескә нык әзерләнә, укучыларда белемгә омтылыш, туры сүзлелек, гаделлек тәрбияли. Туган телнең нечкәлекләрен аңлавына ирешә, дөрес әдәби телдә сөйләшергә өйрәтә.

Роза апа дәресләре кызыклы, мавыктыргыч булып, 45 минут сизелмичә узып китә иде. Ул зур осталык белән татар шагыйрьләренең шигырьләрен укый, укучыларның күңелләренә үк җиткерә белә. Балалар өчен ул яраткан укытучы гына түгел, чын дус, якын кеше дә. Без һәрвакыт аның белән уй-фикерләребезне уртаклаштык, аңа киңәш сорап килдек.

Яраткан апабыз үз вакытын кызганмыйча гел безнең янда булырга тырышты. Тормышыбызда үз юлыбызны табарга булышты, туган телебезне яраттырды.

Ана телен белмәгән, үз телен сөймәгән кеше чын-чынлап башка телләрне дә үзләштерә алмый дигән олы хакыйкатьне безгә Роза апа аңлатты. Бу сүзләр минем өчен юл күрсәтүче йолдыз сыман булды.

*1980*

# ЕВРАЗИЯ КИҢЛЕКЛӘРЕНДӘ

— Безнең болгар бабаларыбызны язмыш Идел ярларыннан Рәсәйнең бөтен киңлекләренә таратты... — дип сөйләде Гөлзада Сафиуллина күптән түгел Казанда үткәрелгән митингларның берсендә. Мин концертларда аның башкарусындагы җырларны яратып тыңлыйм. Сүз дә юк, ул бөтен

җаны белән милли мәдәниятне үстерү, яңарту эшенә бирелгән. Ләкин аның митингта ясаган чыгышы миндә берникадәр канәгатьсезлек уятты. Юк, мин монда җырчыны гаепләргә җыенмыйм. Ул татар халкының тарихын Сталин күрсәтмәләре нигезендә язылган китаплар аша гына күзаллый. ВКП(б) Үзәк Комитетының мәгълүм карарыннан соң татар халкының килеп чыгышын бары тик болгар кабиләсенә генә бәйләп карау киң таралды.

— Без татарлар түгел, ә болгарлар, — дип күкрәк кактылар тарихчыларыбыз һәм шуны алга сөрделәр. Гасыр башында Тукай һәм татар зыялылары кире каккан буталчык идеяне миебезгә чүкеп килделәр. Минемчә бу фикер бүгенге көндә Калуга өлкәсендә яшәүченең: “Мин урыс түгел, мин вятич!” дигән сүзләре белән бер. Калуга җирендә дә бит шундый исемдәге кабилә яшәгән. Урыс милләте дистәләрчә кабилә: древлян, полян, вятич, дрегович һәм башкалардан барлыкка килгән икән, бүгенге көндә Калуга өлкәсендә яшәүче милләте буенча кем булып чыга соң инде? Урыс билгеле. Татар халкының килеп чыгышы нигезендә дә шул ук хәл күзәтелә. Татарлар да бит Евразия киңлекләрендә — Кырымнан алып Тын океанга кадәрле территориядә көн иткән бик күп кабиләләрдән: хазар, Идел болгарлары, кыпчак һ.б.лардан килеп чыкканнар. Бу җирләр — татарларның борын-борыннан гомер сөргән җирләре. Үз чиратында моннан тагын бер фикер агып чыга: Идел буе, Урал вә Себернең абориген халкы — татарлар. Юкка гынамы соң “Татар бугазы” дигән географик атама килеп кергән? Революциядән соң татарларның бик аз өлеше генә үз дәүләтчелеген булдырган. Сталинга ничек кенә булса да үзенең гаделсезлеген акларга кирәк булган, һәм бу дискриминациянең нигезенә, аның идеологик асылы булып патша Россиясе профессорлары тарафыннан ук иҗат ителгән “болгар” әкияте салына. Сталин мәкерле, хәйләкәр булган: ТАССР якынча Идел Болгарстаны территориясе белән тәңгәл килә. Татарларның килеп чыгышын бары тик болгар кабиләсенә генә китереп калдыргач, мишәрләр, Әчтерхан, Себер һәм татар милләтенең башка төркемнәре үз, ата-бабалары җир-

ләрендә килмешәк булалар! Алар милли проблемаларны күтәрүдән вә, билгеле инде, чишүдән мәхрүм.

— Түбәнгә яки Сары Тау (Саратов) якларына юлга чыксак, без үзебез белән капчык-капчык китаплар алып китәбез, — дип кайнарланып дәвам итте Гөлзада Сафиуллина һәм митингта катнашучыларны да "язмыш тараткан" милләттәшләребез турында кайгыртырга өндәде. Әмма шунысы аңлашылып җитми: республиканың 1,5 млн. татарына бүлеп бирелә торган акча белән ничек итеп 7 миллион татарның рухи ихтыяҗын канәгатьләндермәк кирәк? Җырчы фикере белән Татар иҗтимагый үзәге әгъзаларының да килешүе гаҗәпләндерде.

Бары тик Казан гына татарның мәркәзе дигән фикер белән дә бәхәсләшергә була. Октябрь революциясенә кадәр һәм аннан соңгы баштагы чорда да Казан татар мәдәнияят үзәкләренең берсен генә тәшкил итте. Аның абруе дистәләрчә гәҗит һәм журналлар нәшер иткән, мәктәп һәм мәдрәсәләр өчен күп санлы кадрлар әзерләгән, милли театрлар эшләгән Уфа, Оренбург, Әчтерхан шәһәрләре белән бертигез дәрәҗәдә генә булган. Без тел һәм мәдәниятне барлык татарларның милли дәүләтчелеген булдыру белән генә саклап кала алабыз. КПСС Үзәк Комитетының милләтара мөнәсәбәтләр буенча үткәрелгән Пленумында да милли җөмһүриятләр, крайлар, өлкә һәм районнар төзү кирәклеге турында басым ясап әйтелде.

Укучылар мине дөрес аңласыннар иде: мин Идел Болгарстанының абруен, бөеклеген инкяр итмим, ә киресенчә аның белән горурланам. Әмма шул ук вакытта болгар компонентына гына өстенлек бирүнең башкаларга зыян китерү исәбенә булуы белән килешергә ярамый. Үзенең белемсезлеге аркасында "варвар татарлар болгар халкын коллыкка төшерделәр" дип сафсата сатучы татар кешесе нинди кызганыч! Шулай ук һәрбер Новгород кешесе дә Мәскәү Русенең Новгородны буйсындыруына сылтап мәскәүлеләрне ерткыч "москальләр" дип гаепләргә мөмкин. Тарихта теләсә нинди үзәкләштерелгән дәүләт көч һәм кан кою бәрабәренә генә барлыкка килгән. Бердәм татар дәүләте Алтын Урданың барлыкка килүе дә шуңа таяна.

Монгол-татарларның изүе турындагы караш та чынбарлыкка туры килми. Беренчедән, монда монголларның берничнди дә катнашы юк диярлек. Мәгълүм ки, Батый гаскәрләре белән нибары дүрт мең монгол гаиләсе күчеп килгән, алары да тиз арада төркиләр арасында "эреп" юкка чыккан. Көньяк-көнчыгыштан болгар кабиләләре белән кардәш кабиләләр хәрәкәт итә. Монголлар, үз чиратында, төрки кабиләләрнең берләшүендә һәм Алтын Урданың барлыкка килүендә детонатор (этәргеч) ролен генә үтәгән. Икенчедән, Л.Н.Гумилев раславынча, бернииди дә изү булмаган. Бары тик феодаль таркаулыкка дучар ителгән Русьнең көчле татар дәүләте белән союзы урнаштырылган. Кызганычка каршы, "татар изүе" турындагы уйдырма мәктәп дәреслекләрендә бүгенге көндә дә үз көчендә әле. Еш кына бу ялган урысларның үзләренә дә ачы җимешләрен бирә. Эстон депутатының швед гәҗитендә бастырган вә шау-шу куптарган мәкаләсе — моның ачык мисалы. Йөзъеллар буена татар вәхшиләре идарә иткән марҗа халкыннан берниди яхшылык та көтәргә кирәкми, — мәкаләнең лейтмотивы әнә шунда. Нәкъ менә русофиллар мохитында евразиялелек юнәлеше — урысларның килеп чыгышын төрек-славянга бәйләп аңлата торган тәгълиматның тууы да тикмәгә түгел. Шуны да искә төшерүе урынлы булыр: XVI гасыр башында хәзерге Рәсәй җирләрендә 5,5 млн. татар һәм 5 млн. урыс яшәгән. Шагыйрь әйткәнчә, теләсә кайсы гына урысны алып кыргычлама, анда татарны табарсың. Пушкинның сүзләре тикмәгә генәме соң?

Болгар "теориясе" турында сөйләгәндә шуны да әйтеп үтми мөмкин түгел: теләсә кайсы эре милләтнең үсешендә бердәмлек (интеграция) һәм сепаратизм (дифференциация) тенденцияләренең көрәше күзәтелә. Рәсәйнең дәүләт машинасы урысларның үз арасындагы сепаратизмын кысрыклады һәм бу уңайдан татарларга төрлечә өстенлек күрсәтте. Үзенә кагылганда держава турында, безгә килгәндә исә — пантюркизм һәм панисламизм турында сөйләнелде. Әллә ничә мәртәбә үзләренең этник мөстәкыйльлекләрен тануны таләп иткән казак һәм поморларны искә төшерик. Яңа җирләрне колонизацияләү, җирле халыкны асси-

миляцияләү һәм табигатьнең башка шартларында яшәүгә күчү урысларда эзсез кала алганмы соң? Милли холык, традицияләр, мәдәният яшәү мохите белән билгеләнә бит.

Табигый ки, татар халкының һәр төркеменең үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Алар төрле диалектларда сөйләшә, кайвакытта кием-салымнары һ.б. белән дә аерыла. Мәгълүм ки, күптөрлелек теләсә нинди бөтенлекнең үсеше өчен кичектергесез шарт булып тора. Далада терлекчелек белән шөгыльләнүче берничә кабиләнең мөстәкыйль башкорт халкы булып аерылып чыгуы татарда дифференциация тенденциясенең ачык мисалы булып тора. Татар халкының әлеге өлешенә патша тарафыннан күрсәтелгән экономик ташламалар да моңа булышлык итә. Самодержавие һәрвакыт инглиз колонизаторларының “Бүлгәлә һәм хакимлек ит!” дигән сүзләрен истә тотып эш иткән.

Мин профессиональ тарихчыларның мине хуплауларына өмет итмим. Мондый караштa торучы өлкән буын тарихчыларның профессионаллар исәбендә кала алуларына шикләнәм. Алар бары тик системабызның сәяси заказын үтәүчеләр генә иде. Яшь тарихчылар да, билгеле, үз укытучыларына каршы чыкмаячаклар. Хәер, тегеләре дә, болары да әлеге мәсьәләгә бертөрле фикерләрен белдерделәр инде. “Болгар әл-Җәдит” клубы тарафыннан оештырылган митингтан соң республикада киң җәелгән дискуссия шул турыда сөйли. “Әлбәттә, без болгарлар. Әмма шул кадәр күп вакыт үтте ки, бу вакыт эчендә без башка, “татар” этнонимын куллануга күнегеп беттек”. Болгар темасына кагылган язмаларның төп эчтәлеге шуннан гыйбарәт иде. “Поезд китте. Бүген инде без татарлар!” — дип сыкрандылар “болгар” язучылары һәм галимнәре.

Шуңа да карамастан, безгә Алтын Урда турында дөресен белергә кирәк! Фән өчен генә түгел. Моны бары тик тарих проблемасы итеп кенә карарга ярамыйдыр. Чөнки бүген үз җиреннән һәм шанлы дәүләтеннән мәхрүм калган халык язмышы хәл ителә.

*1990*

# МИЛЛӘТНЕ БҮЛМӘГЕЗ!

Мин тарихчы түгел, ләкин мине татар халкының язмышы борчый. Шуңа күрә тарихчыларыбызның күкрәк суга-суга: “Без татарлар түгел, без — болгарлар” диюләре белән һич килешә алмыйм. Имеш, татарларның Казан тирәсендәгеләре тәти, әйбәт, урыс белән элек-электән дус яшәгән, ә башкалары вәхши…

Минемчә, Әбрар Кәримуллинның “Татары: этнос и этноним” дигән китабында дөрес кызыклы фикерләр белән бергә ялгыш фикерләр дә бар. Ул да “без яхшы” дигән тезисны исбатларга маташа. Әстерхан, Себер татарлары һәм башкалар начармыни? “Татар” исемен хөрмәтле галим кушамат дип атый, элек татарлар аны танымаган ди. Юк, безнең ата-бабаларыбыз татар сүзеннән хурланмаганнар, ә горурланганнар.

Рәсәй — татар иле ул! Күп кенә атамалар да моның турында сөйли: Саратов (Сары Тау), Царицын (Сары Сын), Тобольск (Тубыл), Байкал (Байкүл) һ.б.

Тарихны дөрес итеп тасвирларга кирәк, кемгәдер ошар өчен язылган тарих кирәк түгел. Ни өчен безнең тарихчылар Казан ханлыгы турында аз язалар, ә Алтын Урда, Кырым вә Әстерхан ханлыклары турында бөтенләй ләм-мим? Алтын Урдада, мәсәлән, мәдәни үсеш гаҗәеп югары була. Бакчасарай гына ни тора! Пушкин хәтта аңа поэма багышлаган. Ә татар язучылары һәм тарихчылары куркалар ахыры…

Безнең галимнәр татар халкын бүләргә бик яраталар. Имеш, бу татарлар мондый булган, башкалары — тегенди. Боларның бабалары бу кабилә, тегеләрнеке — башка… Минем фикерем: милләтне аерырга түгел, ә берләштерергә кирәк. Урысларны да бүлеп бетерергә була бит. Ләкин алар болай эшләми…

*1990*

# ТАТАРЛАР БЕЗ, ТАТАРЛАР!

Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
Кеше үз исмене инкяр итәрме.
Татарлыкта татар углы татармын,
Татар түгел димә — башың ватармын!
*Дәрдемәнд*

Альберт Әсәдуллинның сәнгать сөючеләргә мөрәҗәгатен укып гаҗәпләндем.

— Без союзда яшәүче халыкларга үзебезнең тарихыбызны дөрес итеп сөйләп бирергә тиешбез. Безнең дәүләтебез Болгар булган. Безнең төп бабаларыбыз — болгарлар. Шушыны төшендерү өчен “Мәһди” спектакле белән Бөтенсоюз аренасына чыгарга әзерләнәбез, — ди Альберт абый.

Танылган җырчының бабаларыбызның тарихына борылып кайтуы, һичшиксез, куанычлы хәл. Ул бөтен җаны белән милли мәдәниятне үстерү, яңарту эшенә бирелде. Шуңа күрә мин Альберт абыйны гаепләргә җыенмыйм. Татар халкы турындагы тарихи китаплар нинди аз һәм безнең тарихыбыз нинди мескен итеп тасвирланган! Мескенләндерделәр шул безне. Сталин һәм сталинчылык безне шундый итте.

... Дәһшәтле 1944 елның май ае. Халкыбызның Кырым өлеше үз җиреннән куыла. Шундый ук язмыш бөтен татарларны көтә. Ләкин Сталин һәм аны котыртып торучы, мөселманнарны җаны-тәне белән “яратучы” Микоян хәйран калалар: татар авыллары Литвадан алып Тын океанга кадәр сибелгән ләбаса! Рәсәй җире — татарларның элек-электән гомер сөргән җире. Идел буе, Урал вә Себернең бер абориген халкы — татарлар. Юкка гынамы соң Ерак Көнчыгыштагы бугаз “Татар” исемен йөртә? “Халыклар атасы”ның нияте тормышка ашмый. Бөтен Рәсәйне диярлек ялангач калдырып булмый бит инде!

Менә шунда патша Россиясе профессорлары тарафыннан ук иҗат ителгән һәм гасыр башында Тукай вә татар зыяллары кире каккан “Болгар” әкияте яңадан торгызыла.

ВКП(б) Үзәк Комитеты август аенда татар халкы турында махсус карар кабул итә. Сталин татар халкының килеп чыгышын бары тик болгар кабиләсенә генә бәйләп карарга әмер бирә. Халкыбызның бөтен Алтын Урда белән бәйләнгән тарихы барлык китаплардан сызып ташлана. Татар милләте мескен, кечкенә итеп тасвирлана башлый. Аның Алтын Урда кебек көчле, бөтен Евразияне диярлек үз кулында тоткан дәүләте булуы мөмкин түгел, дип исбат итәргә тырышыла.

— Сез — болгарлар. Сезнең Татарстаныгыз Идел Болгарстаны территориясе белән тәңгәл килә, — диләр безгә.

Димәк, татарларның күпчелеге үз ата-бабалары гомер-гомергә яшәгән җирләрендә килмешәк дип игълан ителә. Безнең депутатлар бүген съезд трибунасыннан: “Халкыбыз Идел ярларыннан бөтен Рәсәйгә сибелде”, дип юкка гына сөйләмиләр шул.

И, Сталин, син нинди мәкерле, хәйләкәр, “алдан күрүчән” булгансың: минем бердәм халкымны кырыкка бүлгәнсең! Казан тирәсендә яшәүче татарлар “болгар халкы” булды, мишәрләр — кыпчак, әчтерханнар нугайга әйләнделәр, ә Себер татарлары инде, кысык күзле булганга, монгол-лардыр... Тарихны кирегә борып булмый, диләр. Ә татар милләтен киредән кабиләләргә бүлү? Башта самодержавие, аннары сталинчылык һәрчак инглиз колонизаторларының “Бүлгәлә һәм хакимлек ит!” дигән канунын истә тотып эш иткәннәр вә зур уңышларга ирешкәннәр.

Урыс милләте дистәләрчә кабиләләр кушылудан барлыкка килгән. Татар халкының килеп чыгышы нигезендә дә шул ук хәл күзәтелә.

Борын-борын заманда Ока елгасы ярларында вятичлар кабиләсе яшәгән. Көннәрнең берендә бүгенге Калуга өлкә-сенең урысы: “Мин урыс түгел, мин вятич!” дисә, бот чабып көләр идең, кадерле укучым.

Кайберәүләр:

— Без татарлар түгел, ә болгарлар, — дип күкрәк какканда, тыныч кына карап торасың. Әнә алар, хәтта конгрессларын үткәрделәр. Котыбыз алынган шул безнең. “Татар” сүзе “вәхши”нең синонимына әйләндерелде бит! Хәтта Татарстанда милләтләрен яшерергә, исемнән качарга

тырышалар. Ә Рязань татарлары нишләсен инде? “Татарская морда” дигәнне ишетәсе килми шул. Һәр аерым урыска татар изүе булмаганны, киресенчә, феодаль таркаулыкка дучар ителгән Русьның көчле татар дәүләте белән союз урнаштырылганын аңлатып булмый ич! Урыслар Александр Невский Батыйның тәрбиягә алынган улы икәнен белми бит! Кызганычка каршы, “татар изүе” турындагы уйдырма мәктәп дәреслекләрендә бүгенге көндә дә үз көчендә әле. Ә Л.Н.Гумилев әсәрләре белгечләргә генә билгеле. Эх, үз гумилевларыбыз юк шул безнең! Юкса бөтен тарихыбызны чынбарлыгы белән бөтен дөньяга күптән сөйләп биргән булыр идек.

Без үзебезне ата-бабаларыбыз исеменә, халкыбыз тарихына хыянәт итеп, аклый алмыйбыз. Уйлап карасаң, немец та “фашист” сүзен искә төшерә. Ләкин алманнар без түгел шул. Алар кемгәдер яхшы булып күренер өчен милләтләреннән баш тартмыйлар. Киресенчә, бөтен киртәләрне җиңеп, берләшәләр. Бүген Казан татарларының бер өлеше тәти булып күренергә тырыша, мишәрләр, Әчтерхан, Себер татарларын булмаган гөнаһларда гаепли. Ә бәлки, безгә дә акланырга, бер-беребезне рәнҗетергә кирәкмидер? Бәлки, тарихыбызны танып, аның белән горурланып яшәргә кирәктер? Татар бит беркайчан да төшеп калганнардан булмаган! Батый кебек ханнарыбыз урта гасырларда дөньяны дерелдәтеп торганнар, соңрак татар керәшене Борис Годуновтан, алты мәртәбә ялварып, тәхеткә утыруын сораганнар — ул татарга элек-электән хас булган акылы, гаделлеге, сабырлыгы белән дан казанган. Рус империясе заманында татарлар Рәсәйнең барлык капиталының өчтән бер өлешенә ия булганнар. Бүген чит илләрдә дә алар сәүдәгәрләр, галимнәр. Һәркем үз эшенең остасы, хөрмәт ителә торган кеше.

*1991*

# ШӘРЫККА БОРЫЛСАК — ЯЛГЫШМАБЫЗ...

Ике-өч ел элек Казан университетының бер төркем студенты югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләсен куйды. Аларның мөрәҗәгате листовка формасында чыкты һәм татарлар яши торган барлык төбәкләргә таралды. Студентлар киң җәмәгатьчелектә яклау таптылар. Ата-аналарны без күпме генә балаларын татар мәктәпләренә бирергә үгетләсәк тә, алар анда борылырга ашыкмады. Чөнки һәрбер кеше баланың киләчәге турында да уйлый. Ә ул киләчәк белем алу белән дә бәйле... Хәзер хәлләр уңай якка үзгәрә. Институтларның берничәсендә татарча белем алу мөмкинлеге тудырылды, андыйларның саны елдан-ел арта. Шуның нәтиҗәсендә Казанда һәм башка калаларда татар гимназияләре ачылды. Аларда укыр өчен хәтта ки конкурс аша узарга кирәк.

Гомумән, үз телендә югары белем бирә алмаган милләтнең киләчәге юк икәне бүген көн кебек ачык. Шуңа күрә безгә институтларыбызны кулдан ычкындырырга һич ярамый. Ә суверенитет турында Декларация кабул иткәннән бирле инде, югары уку йортларыбызның күпчелеге ябыла, дигән имеш-мимешләр йөри. Рәсәй аларны финансларга теләми. Безнең завод-фабрикаларыбызда алынган табыш элеккечә Мәскәүгә китә. Үз байлыкларыбызга да хуҗа түгел әле без. Шуңа күрә Татарстан барлык вузларын да үз җилкәсенә ала алмый.

Тирәнрәк уйлап караганда, безнең белгечләр Рәсәйгә кирәкмәячәк тә. Базар экономикасы белгеч алдына бөтенләй башка таләпләр куя. Эшмәкәрләр Көнбатышка белем алырга юкка гына ашкынмыйлар. Мондый шартларда урысларның зур акчалар түләп бездә белем алырга килүләре бик шикле. Ә акчасыз вуз яши алмаячак. Чөнки иртәгә ул дәүләт җилкәсеннән үзе тапкан акча нигезенә күчәчәк. Димәк, базар мөнәсәбәтләре уку йортларыбызны саклап калмаячак, киресенчә, аларның хәлен кискенләштерәчәк.

Нәтиҗә нинди соң? Күпсанлы галимнәр эшсез калачак.

Һәм бу табигый. Вуз укытучыларының күпчелеге урыс һәм яһүдләр. Мәскәү аларны Татарстан җирендә үзенең терәге итеп карый. Аңлашыла ки, бу адым мәсьәләне хәл итми.

Теләсә-теләмәсәләр дә, мөгаллимнәребезнең байтагына эш эзләргә туры киләчәк, ахры. Калдырылган уку йортларында урыс һәм татар бүлекләре булачак һәм эш мәсьәләсендә ике тел белгән укытучыларга, билгеле, өстенлек биреләчәк, дип уйлыйм. Урыс коллегаларыбызның кайбере моны аңлап бетерми әле. Аларга урнаштырылган бер теллелек мәңге сакланачак кебек тоела. Менә урысның татарга өстән аска карау гадәте югары уку йортларыбызны саклап калырга комачаулый да, минемчә. Дистәләгән институтның барысын да калдырырга мөмкин. Аның өчен укытучыларыбызның күпчелегенең татарча белүе генә таләп ителә. Октябрьгә кадәр татар мәдрәсәләрендә үзбәге дә, кыргызы да, башкасы да — барлык төркиләр укыган. Нигә шул традицияне торгызмаска? Нигә башка төрки җөмһүриятләргә кадрлар әзерләүгә алынмаска? Акчага инде, билгеле. Шул ук Урта Азиядә югары уку йортлары аз. Булганнарында да укыту сыйфаты түбән. Шуңа күрә төркиләр укырга Рәсәйгә, Украинага юл тоталар. Аларның бар көчләре диярлек урыс телен өйрәнүгә китә. Бездә хәзер укып йөрүче вьетнамлылардан үзбәкләр күпкә аерылмый. Тегеләре дә, болары да фән, белгечлек үзләштерергә бирелгән вакытны урыс теле белән газапланып уздыра. Нәтиҗәдә күпләре элек булган белемнәрен дә җуеп кайта. Татар теле төрки телләр арасында иң универсаль тел дип исәпләнә. Төрки-татар телендә Урта Азия яшьләре шатланып укыр иде. Димәк, безгә булган фәнни һәм педагогик потенциалны татар теленә күчереп, шундый мөмкинлек тудырырга кирәк.

Аңлыйм, моны язасы гына җиңелдер. Урыс татар телендә укытсын әле! Шулай да, без, татарлар, дәресләрне урысча алып барабыз бит. Нигә алар безнең телне исәпләмәскә тиеш? Институт ябылу куркынычы килеп басса, татар телен бик теләп өйрәнерләр, дип уйлыйм. Әллә ни авыр эш түгел ул. Әнә Казан университеты мөгаллимнәре Мәскәүдә инглиз, француз телен өч ай үзләштерәләр дә, чит илләрдә лекцияләр укып йөриләр. Студент чагымда хәзер инде мәрхүм

профессор Лаптевтан татарча укытыр идегезме, дип сораган идем. Кирәк булса, мин разый диде. Шул, кирәк булган чак җитте бугай.

Ләкин техник фәннәр вәкилләре минем белән килешеп бетмәсләр. Урта Азия — зур мамык плантациясе ул, диярләр. КАИ, йә КХТИ бетергән кеше анда нишләр? Киләчәккә карап эш итәргә кирәк. Чөнки ул мамыкны бездә армия таләбе буенча үстерделәр. Хәзер инде сер түгел, мамык — шартлату җайланмалары җитештерүдә төп компонент булып тора. Бүген исә бездә конверсия процессы бара. Корал җитештерү күпкә кими. Шуңа күрә мамык республикалары хәзер үзләрендә промышленность булдыруга юл алдылар. Анда техник белгечләр кирәк булачак.

Институтларыбызның язмышы бүгенгәчә ачык түгел. Кайсы юлдан китәргә? Бөтен булган вариантларны карарга кирәк. Мин менә кыйбланы Шәрыкка тотсак, ялгышмабыз дип уйлыйм.

*1991*

# КАЗАН ХАТЫННАРЫ

Урамнарда йә җәмәгать транспортында кайбер Казан хатыннарын күреп, авыл кешесе гаҗәпләнеп куя. Үзләре татарлар бугай, ләкин сөйләшүләре ике тел боткасы, чәчләрен кыска иттереп кистергәннәр, инде әби булганнары да иреннәренә куе иннек сөрткәннәр. Татар хатыннарының мондый кыяфәте бик тә сәер...

Казан хатыны авыл кешесенә кәпрәеп карый, марҗа ахирәтен исә алдынгы, культуралы дип исәпли. Һәм аңа охшарга тырыша. Хәтта ки аны уздырып та җибәрә.

Мәҗлесләрдә ул, организмдагы микробларын үтерә, дигән сылтау белән ике-өч рюмка аракы да җиффәрә. Шуннан соң симез битләре кызарып китә. Янындагы чандыр Мәхмүте йә Әхмәте, форсаттан файдаланып, ашау турында онытып эчә. Һәм тиздән ләх була...

Күпчелек очракта алар шыр надан. Аларны заманында Ленин иң мәгърифәтле халык дип атаган татарның кызлары дип һич уйламассың. Гәҗит-журналларны сирәк укыйлар.

“Вечерняя Казань”ны мактыйлар, эштә, күрегез, мин националистка түгел, дигәндәй, беренчеләрдән шуңа язылалар. Үз ишләре белән җыелышып Фәүзия Бәйрәмованы сүгәләр, урыслардан башка — үз җиреңә үзең хуҗа булып яшәүне күз алларына да китермиләр.

Балалары белән аралашулары үзе бер кәмит. Ана татарча әйтә, баласы урысча җавап кайтара. Димәк, уллары-кызлары маэмай кебек — ана телен аңлыйлар, ләкин сөйли алмыйлар.

— Нигә балагызны татарча сөйләштермисез? — дип сорасаң:

— Нәрсәгә кирәк ул? — диләр. — Үзем гомер буе урысча җүнләп белмәү аркасында җиңел эштә эшләмәдем, балаларым ичмаса укып нәчәлник булсыннар. Татар теле башларын гына бутый...

Мондый сүзләрдә хаклык та бар. Казан каласындагы дистәләгән училищеның, техникумның, югары уку йортының берсендә дә татарча укытмыйлар. Казан татарының бөтен иҗтимагый тормышы урыс телендә уза, диярлек.

Саңгырау белән телсез кебек аралашып, Казан хатыны баласына тиешле тәрбия бирә алмый, билгеле. Яшүсмерләр, берләшеп, урамнарда кеше кыйнап-талап йөри. Ул төркемнәр “группировкалар” дип атала, ә бу күренеш үзе “Казан феномены” дип. Үсеп җиткәч, Казан маңкорты анасына еш кына: “Чаплашка”, — ди...

Кагыйдә буларак, Казан хатыны үзен бәхетсез иткән сәвит системасын, сәвит законнарын җаны-тәне белән яклый. Ә исламны кабул итми. Бу аңлашыла да, чөнки сәвит кануннары ир-атны хатын колы итте, чүпрәккә әйләндерде. Кыз бала, әнисенең әтисенә булган мөнәсәбәтен күреп, азыптузып үсә. Аның итәге кыска, парфюмерияне ул мул куллана. Кайсылары гыйффәтлегеннән алтынчы-җиденче сыйныфта ук “арына”. Хәтта байларның да кызлары кайвакыт фәхишәлек белән шөгыльләнә... Кызының оятсыз, эгоист булып үсүен Казан хатыны эченнән генә хуплый, хәзер тормышта шундыйлар гына бәхетле, дип исәпли. Бу фәлсәфә еш кына аклана да. “Асыл кош” урыс егетенең

башын әйләндереп кияүгә чыга, аны җигеп тормыш итә. Ләкин күп гаиләләр тиз таркала.

Элек-электән авылдан хәерче, сәләтсез гаиләләр күчеп киткән. Өлкән буын Казан хатыннарының күпләре — коммун балалары. Алар авыл кыенлыкларыннан качтылар. Аларның аталары, кулларына наган тотып, крестьяннардан “яңа тормыш” төзеттеләр. Шәһәр әбиләренең наданлыгы шул зимагорлардан киләдер. Аннары милләтнең укымышлы өлеше дәһшәтле елларда юк ителде. Ә күзлек киеп гарәп-фарсы китаплары укып утыручы ыспай абыстайларның кызлары Финляндиядә йә Австралиядә генә (гомумән, чит илләрдә генә) исән калды. Сабый чакларында аларны Аллаһы Тәгалә саклады. Универсамнарда озын чиратларда торганда, Казан әбиләре Сталинны сагына, тәртип юк, дип зарлана. Ленин идеяләре аларга геннар аша сеңгән...

Картая башлагач, кешенең мәңгегә килмәгәнен аңлагач, алар Аллаһыны искә төшерәләр, мәчеткә юнәләләр. Анда гомерләрен партиягә, коммунизм төзүгә багышлаган бабайлардан “әссәламегаләйкем” дип исәнләшергә өйрәнәләр. Исәнләшүнең бу ысулын мөселман халыкларында ир-атлар гына кулланса да, динсез хатыннарның мәчеткә йөрүләре мактауга лаек. Татар хатыннарының сыраханәләр янында әшәке сүгенеп чиратта торуын күрү бик авыр...

Күбесенең картлык көннәре аянычлы. Хәләл җефетеннән җылы сүз ишетмәгән, рәтләп ашап-эчмәгән, гомумән, тәрбия күрмәгән шәһәр карты теге дөньяга алданрак китеп бара. Карчык ялгыз кала һәм күп җәфа чигә. Килен марҗа, углан маңкорт — көт син алардан мәрхәмәт! Үзе өчен генә яши торган кызы Эмма-Клара исә ялгыз әнисе турында уйлап та карамый.

Казан каласында, күрше-күлән дә кереп йөрмәгән фатирларда, ялгыз карт кешеләрнең мәетләре айлар буе череп яту очраклары ешая...

*1992*

# ҺӘЛАКӘТ

Татар теле — төрки тел, татар төркиләренең ана теле. Бу телне белеп күп җирләрне гизәргә вә анда яшәгән халыклар белән аңлашырга була.

Урта гасырларда татарның данлы Алтын Урда дәүләте чәчәк атканда, телебез бүгенге инглиз теле кебек гаять киң тарала, бөтен дөнья тормышында зур роль уйный. Мәсәлән, ул чорда татар телен белми, халыкара сәүдә алып бару мөмкин булмый.

Әмма еллар үтә, гасырлар кичә, бердәм татар дәүләте таркала, вак ханлыклар барлыкка килә. Аерылганы — аю, бүленгәнне бүре ашар, ди. Күп вакыт та үтми татар ханлыкларын урыс дәүләте йотып бетерә. Татар теле, барлык дәүләтсез милләтләрнең телләре белән беррәттән, үлемгә дучар ителә. 1917 елгы инкыйлабтан соң, коммунистлар аны тәмам үлем түшәгенә салалар.

Бүген татар теле җанын бирә. Кызганыч, бу телдә хәтта ки өзлексез белем алу мөкинлеге дә юк. Татар мәктәпләре бар барын, әмма анда укучылар бик аз. Мәктәп — тормышыбызның башы гына шул. Аны тәмамлап һөнәр үзләштерәсе йә берәр белгечлек аласы бар. Ә барлык училище, техникум һәм институтта укыту фәкать урысча. Күпмиллионлы татар халкының бер генә дә милли университеты юк. Шуңа күрә ата-аналар татар мәктәбен читләтеп узалар, балаларын җитәкләп урыс мәктәбенә юл тоталар.

— Татар телендә космонавт та, химия галиме дә, хәтта токарь да булалмагач, кинотеатрга кереп кино күрәлмәгәч, телевизордан мексикалы “гади генә” Мариянең тавышын ишетмәгәч, эштә сөйләшмәгәч нигә кирәк соң ул? — ди татар абзые һәм ирексездән баласы илә вата-сындыра урысча сөйләшә.

XX гасыр азагында илһамланып татарча шигырьләр вә романнар язган, татар җырларын көйләгән, милли аңга ия соңгы буын яши бугай. Аларның балалары урыс җырын җырлап, Пушкин вә Лермонтов шигырьләрен ятлап, Рәсәй тарихын үзләштереп, җаннарына урыс рухын сеңдереп үсә. Иваннар санына алардан һич берничек тә аерылмаган Рамилләр вә Маратлар өстәлә.

Шундый татар исем-фамилияле урыс балалары бүген Төркиягә укырга җибәрелә. Һәммәсе дә түгел, әлбәттә, бәгъзеләре. Ана телен белмәгән, авызына тәмәке белән эчке алган, әшәке сүгенгән егетләр һәм мини итәк сөйгән кызларны күреп кардәшләребез шакката. “Без татарларны сорадык, сез урыс балаларын җибәрәсез”, — дип ризасызлык белдерә.

Ә башкалары юк диярлек. Авылларда саф ана телендә сөйләшкән балалар юк түгел үзе. Әмма крәстиян баласына чит илләрдә уку бәхете тәтеми шул... Авыл дигәннән, анда да бүген татар рухы сүнеп бара. Элек татар авылы, Америка индеецлары резервациясе сыман, изоляциядә яшәде. Юллар юк, көне-төне урысча такылдаган телевизор-радио юк, Казанга китеп урыслашырга паспорт та юк. Соңгысы бирелмәде. Халык үз телендә яшәде: эшләде, бәйрәмнәрдә вә елга буендагы кичке уеннарда күңел ачты, үз милләте белән гаилә корып үрчеде. Авыл артистларыбызны, шагыйрьләребезне, язучы вә галимнәребезне үстереп бирде. 60-70 нче елларда авыл халкының күпчелеге шәһәрләргә таралаша, калганнары исә чиркәү каккан телевизор каршысына килеп утыра. Аракы эчеп, кәефләнеп “өлкән туган” культурасына соклана. Шулай итеп, татар мохите тәмам юкка чыгарыла, милләтнең соңгы өмете өзелә. И хакыйкать, бик гади дә син, күтәрә алмаслык авыр да...

*1993*

## ХУҖА НАСРЕТДИН КЕМНЕКЕ?

Төрекләр җор халык. Мәзәк, кечкенә көлкеле әсәрләр яраталар. Анекдотка алар “фыкра” диләр һәм аны чәйханәләрендә сәгатьләр буе сиптерәләр. Элек киң кулланылган “фикъръә” сүзен инде онытсак та, мәзәкне яратабыз без дә. Шулай берзаман арабызда хәтта бәхәс купты. Безнең Хуҗа Насретдинга төрекләр хуҗа булмакчылар. Ул төрек һәм Конья вилаятендә яшәгән имеш.

— Сезнеке булса, мәзәкләрен сөйләп күрсәтегез, — дидек без, татарлар. Вә үкендек. Хуҗа Насретдин мәзәкләре аларда бихисап икән. Бер-икесен укучыларга да тәкъдим итәргә мөмкин.

* * *

## Үзенә генә күңелсез

Көннәрнең берендә вали* балачагын, туган авылын искә төшерә. Күңеле хатирәләрдән арынып, кабинетына кайткач, ул авылдашларына бер бүләк тапшырырга була. Әмма ни бирергә мөмкин? Ярдәмчеләре тәкъдим иткән һәрнәрсә валига вак, дәрәҗәсен генә төшерә кебек тоела. Шулай да, кат-кат киңәшмәләр үткәреп табалар һәдиясен. Вали туган авылына Африкадан фил кайтарта. Филне карарга барлык тирә-яктан киләләр. Халык бүләккә бик сөенә, мәшһүр якташы белән горурлана.

Ләкин шәп нәрсә күп булмый дигән кебек, бу шатлык та озакка сузылмый. Фил күп ашый, аңа ризык җиткезеп булмый. Авыл халкы кайгыга чума. Нишләргә? Валига, Бүләгең кирәкми, кире ал, — дип булмый ич. Ә фил дөньяны куркытып акыра, ашарга сорый. Бөтенләй чыдарлык хәл калмагач, Хуҗа Насретдин янына килеп ялваралар:

— Зинһар, коткар. Әйт валига, алсын бездән филен.

— Вали да әллә кем түгел, безнең кебек үк кеше инде. Ризамын, ләкин сәяхәтем күңеллерәк булсын өчен минем белән 3-4 кеше барсын,— ди Хуҗа. — Бергәләп валига керербез. Мин сөйләрмен, ә алар арттан “әйе”, “әйе” дип торырлар.

Җыелышып китәләр. Вали сараена якынлашкан саен, илчеләрнең тезләре көчлерәк калтырый. Хуҗа Насретдин гына кыю. Туп-туры вали янына кереп китә ул килү белән. Юлдашлары исә ишек артында качып кала.

— Хуш килдең, Насретдин Хуҗа. Нинди гозерең бар, — дип каршылый вали.

— Олы бүләгең авылыбызны бөтен тирә-якка данлы итте. Сөенеп туя алмыйбыз. Рәхмәтләребезне белдерәбез, — дигән булып салпы ягына салам кыстыра Хуҗа һәм хуплау сүзләре килмәгәнгә аптырап уңга-сулга карана. Илчеләр юк.

— Туган җиремә мин үзем мәңге бурычлымын. Рәхмәтләр кирәкмәс, — ди вали. — Тагын ни җибәрим?

---

* вали — дәүләтнең бер өлешен идарә итүче, губернатор

Хуҗа җавап бирә:

— Филебез ялгыз. Үзенә генә күңелсез. Вали бәй, мөмкин булса, тагын ана фил дә кайтарт...

**Йортыбыз киңәйде**

Ярлы тормышын сөйрәүче бер адәм Хуҗа Насретдин янына килә. Ата-анасы, хатыны һәм балалары белән кечкенә йортта яшәү авыр моңа.

— Хуҗа, сыймыйбыз, нишләргә? — ди.

— Тавыкларыгыз булса, шуларны өйгә алып кереп урнаштыр, — дип киңәш бирә Хуҗа Насретдин.

Ике-өч көннән соң бу адәм тагын Хуҗаны эзләп таба. "Тормышыбыз авырайды гына, тәкъдимең ярдәм итмәде", — ди. Тапкыр картның исә яңа киңәше әзер: кәҗәне дә өйгә кертергә. Билгеле инде, бу бер дә файдага бармый. Адәмнең зарлануын ишетеп:

— Алайса, сыерыгызны да кертегез, — ди Хуҗа Насретдин.

Сыер да кергәч, болай да кысрык җирдә бөтенләй урын калмый.

— Түзәрлек хәлебез тәмам, — ди адәм.

Хуҗа бичараны җәлләп сыерны өйдән чыгарырга тәкъдим итә. Өйдәгеләр җиңел сулап куя. Моны ишетеп, Хуҗа Насретдин кәҗәне дә чыгарырга куша. Тормыш тагын да җиңеләя. Тавыклар да үз урыннарына кунгач, йорт хуҗасы Насретдинга:

— Хайваннар чыккач, йортыбыз киңәйде. Хәзер шөкер, сыябыз инде, — дигән ди имеш...

*1994*

# "ТЕЛДӘ, ФИКЕРДӘ, ЭШТӘ БЕРЛЕК"

Татарлар, ЮНЕСКО мәгълүматлары буенча, Җир шарының төрле төбәкләрендә яшиләр, татар теле исә күп кенә башка халыклар белән аралашу мөмкинлеген бирә. Шуңа күрә, татар телен галимнәр инглиз, алман, гарәп һәм башка киң таралган ундүрт тел рәтендә күрсәтәләр. Татарлар чит җирләргә төпләнеп, үзләренең тырышканлыклары белән югары мәртәбәләргә

ирешәләр. Күп кенә илләрдә татардан чыккан галимнәр, дәүләт вә җәмәгать эшлеклеләре, эшмәкәрләр, язучылар лаеклы, хөрмәтле кешеләр булып саналалар.

Билгеле булганча, Кырым, Идел-Урал вә Көнбатыш Себер — татарның төп ватаны. Татар, милләт буларак, шушы киңлекләрдә оеша башлый. Әмма Алтын Урда таркалып, аның җирләрен урыслар басып алгач, бу процесс сүлпәнләнә.

Чит-ят җирләргә татарның зур бер төркеме үз дәүләте исән-имин чагында ук китеп бара. XIV гасыр ахырында Литваның бөек кенәзе кыю, батыр татар гаскәриләрен хезмәткә чакыра һәм ялгышмый. Атаклы Грюнвальд явында татарлар хәлиткеч роль уйныйлар. Милләттәшләребез җирле халыкның мәхәббәтен яулап, шунда төпләнеп калалар.

Татар ханлыклары җимерелгәч, читкә китү киң колач җәя. Моның төп сәбәбе — урыс залимнәре тарафыннан милли вә дини җәберләүләр була. Рәсәй халыклар төрмәсе буларак танылa. Шул рәвешле, кайчандыр Мәскәүдән күпкә көчле дәүләте булган татарлар еш кына физик юк ителәләр. Рәсәй империясе алар өчен карцер була, ягъни зиндан эчендәге зиндан. Татарлар күпләп казакъ далаларына, аннан уйгур җирләренә, Анадолу кардәшләре янына качалар. Бүген фарсы йә гарәп мәмләкәтләренә күпме татар килеп чыкканын төгәл әйтеп тә булмый инде. Әмма бүгенге төрекләр, гарәпләр, фарсыларның тамырларында татар каны да агуы бәхәссез.

Рәсәй чорында татарларның күпләп күченүләрен өч өлешкә бүлеп карарга мөмкин.

1897 елда Рәсәй Манчжуриядә Чин шәрекъ тимер юлын (КВЖД) төзүгә керешә. Татарлар төзелешкә күпләп китә, башта Шәркы Русиядән, соңрак үзәк төбәкләрдән. XX гасыр башында алар Корея белән Япунга да үтеп керәләр, әмма мөһаҗирләрнең язмышы аяныч була. Икенче бөтендөнья сугышы азагында бу җирләргә совет гаскәрләре бәреп керә, татарлар күпләп үтерелә, башкалары исә Төркия һәм АКШка качып котыла.

Мөһаҗирләрнең икенче зур бер төркеме Финляндиядә төпләнә. XIX гасырның икенче яртысында Финляндия Рәсәй империясенең бер өлеше булып тора. Суоми мәмләкәтенә беренчеләрдән булып Нижгардан Сергач мишәрләре килә. Бүген татарлар Хельсинки, Тампере, Турку һ.б.

шәһәрләрдә яшиләр. Мәсләкләре — мишәрләргә хас булган сәүдәгәрлек. Араларында галимнәр, укытучылар, табиблар да юк түгел. Төрле чыганаклар буенча, аларның гомуми саны 1000 нән алып, 4-5 меңгә чаклы.

Өченче зур күченеш шулай ук XIX гасырның икенче яртысы белән бәйле: татарлар күпләп Төркиягә китә. Соңрак, 1945 елдан соң, аларга Ерак Көнчыгыштан качаклар кушыла. Шул сәбәпле милләттәшләребезне гади төрекләр берникадәр вакыт чин төрекләре дип тә атыйлар. Төркиянең 90 процент татары тарихи ватанын 1917 елдан соң ташларга мәҗбүр булды дип яза Ф. Хәкимҗанов (“Мирас”, 1992, 5 сан, 116 б.).

35,9 процент Төркия татары Рәсәйдә, 45,9 проценты Кытайда, 18,2 проценты Төркиядә, Японоиядә, Кореядә туган.

Шулай да Төркия татарларының төгәл санын күрсәтү бик кыен. 1917 елга кадәр төркиләрнең үзара багланышлары нык була. Алар арасында татар, казакъ, үзбәк вә башка халыкларга бүленеш булмый, алар бербөтен “мөселман”, “төрек” халкын тәшкил итәләр. Әдәби тел дә уртак була. Истанбул, Каһирә, Бакчасарай һ. б. шәһәрләрдә нәшер ителгән китап вә гәҗитләр Казанда укыла һәм, киресенчә, Казан басмалары башка регионнарга тарала. Ул чорда Урта Азия вә Казакъстан төрекләренең балаларын, нигездә казанлылар укыта. Үз нәүбәтендә, аларның угланнары югары белемне Госманлы дәүләтенең Истанбул, Каһирә һ.б. фәнни үзәкләрендә ала. Патша хөкүмәтенең каршылык күрсәтүенә карамастан, безнең фикеребезчә, төрек этносы әкрен, әмма дугру интеграция юлы буенча үсә.

Гомумән, барлык эре этник берлекләрдә ике якның каршылыгын күрсәтергә мөмкин. Ике үсеш юнәлеше — дифференциация (аерылышу, бүленү, таркалу) һәм интеграция (берләшү, кушылу) — үзара көрәштә яши. Этнос оешу чорында Бөек Төрек каханлыгы төрекләрне бергә туплый. Соңрак, Евразия континентында төрекләрнең киң таралуы аркасында, таркалу юнәлеше өстенлек ала. Мөстәкыйль каханлыклар барлыкка килә. XIII гасырда бүленү тәмамлана. Алтын Урда чорында төрек тарихы биеккә үрмәләп, интеграциянең югары ноктасына килеп җитә. Шуннан соңгы елларда үзәкләштерелгән дәүләтнең таркалуы

башка этнос вәкилләренә төрек җирләрен басып алу өчен уңай шартлар тудыра. Бу вакыйга төрекләрнең тарихына кире йогынты ясый. Ләкин шуңа да карамастан, этносның алга таба үсеше дәвам итә. Рәсәй яулап алган җирләрдә төрекләр үз тормышлары, үз дөньялары белән яшиләр. Алар дүрт гасыр эчендә яулап алучылар арасында югалмыйлар, чөнки Рәсәй төрекләренең үз... дәүләтләре була. Шундый дәүләт мәнфәгатьләрен Ислам үзенә алган. Исламны дин буларак кына карарга ярамый. Ислам ул тәгълимат кенә түгел, ә кешенең яшәү рәвеше. Ул мөселман тормышының барлык якларын үз эченә ала, аның һәр адымын билгели. Рәсәй төрекләре урыс патшасының кул астында булганнар, әмма Исламга буйсынганнар. Ислам һәм төрек дөньясы белән тыгыз элемтәләр этносның бәхетсез өлешен саклап калырга ярдәм иткән. Шуның белән бөтен төрек дөньясының бөтенлеге сакланып калынган. Безнең уебызча, XX гасыр башында этносыбызның югары үсеш чорына җитүе өчен барлык шартлар да тудырылган иде. Гарәп милләте бер, әмма гарәп дәүләтләре күп. Бербөтен төрек милләте дә төрле дәүләтләрдә яшәп, үзенең бөтенлеген саклап кала алыр иде.

Ул вакытта Госманлы дәүләте бөтен төрекләрнең уртак дәүләте булып саналуын да онытмаска кирәк. Илнең үзәк өлешенең бер илчәсендә (районында) шундый күренеш күз алдына килеп баса. Чифтәләр илчәсе Искешәһәр вилаятендә урнашкан, ә Искешәһәрдән Әнкарага автобус белән бару өчен 2-3 сәгать вакыт җитә. Илчәдә 30дан артык шәһәр вә авыл бар.

1914 елда Болгариядән күчеп килүчеләр Аббасхалимпаша авылын төзиләр. Агларҗа авылын Кавказдан килгән чиркәсләр төзи, бүгенге көнгә кадәр анда яшәүчеләр бабаларыннан калган гадәтләргә тугрылыклы булып калганнар, Кавказ мәдәниятенең күп кенә өлешләре сакланган. Акдерә авылы картада 1880—1890 елларда пәйда була, анда төрекмәннәр яши. Аккисар авылы крестьяннары кавказлылар нәселеннән, алар 1887 елда Анадолуга күчәләр. Арсланлы авылының тарихы ерак гасырларны эченә ала (бу турыда арслан таш һәйкәле дә раслый), авылда яшәүчеләр үзләренең бабалары төрекмәннәр булуын яхшы хәтерлиләр. 1892 елда Башара авылына нигез салына. Әмма тиздән аңа нигез

салучылар ул авылны ташлап китәләр, Кавказдан чиркәсләр килгәч кенә, тормыш яңадан башлана. Башкурт авылы үзенең яшәү урынын берничә тапкыр үзгәртә. Бу авылга Румыниядән килгән татарлар нигез сала. Авылны төзүдә 1928—1929 елларда Болгария вә Румыниядән качкан төрекләр дә үз өлешләрен кертәләр. 1898—1905 елларда Кавказдан качкан карачайлар Бәлпынар авылын төзиләр, алар шулай ук бабаларының гореф-гадәтләрен саклап калу өчен зур тырышлык куялар. Гаилә кешеләре арасындагы мөнәсәбәтләрдә бернинди үзгәрешләр юк диярлек. 300 ел элек Анадолуга килгән төрекмәннәр Чатмапынар авылына нигез салалар. Хәзерге вакытта анда 300 ләп кеше яши.

Дикиликайа авылында яшәүче аксакаллар түбәндәгеләрне сөйлиләр: 1848 елда төрекмәннәр Урта Азияне калдырып, Анадолу буенча йөргәннән соң, кемдер тарафыннан язылган гаять зур мәрмәр кыя янында төпләнергә булалар. Менә шуңа күрә бу авыл шулай дип атала (кайа — кыя, таш; дикили — корылган). Болгариядән килгән мөһаҗирләр 1887 елда Дикмән авылын нигезлиләр. Бер-береннән ерак булмаган Янтуган, Ортакөй вә Доганай авылларына Ганҗадан килгән әзари төрекләре нигез сала. Соңга таба бу авылга Болгариядән килгән качаклар күчә, күрше авылдан төрекмәннәр дә килә. Әминәкин авылы 1630 елдан ук билгеле. 1920 елда монда Селаниктан (Греция) мөһаҗирләр күчеп килә. XIX гасырның ахырларында күрше Хан шәһәрендә яшәүчеләр Гюкчекуйу авылына нигез салалар. Авылның әйләнә-тирәсендә хетт заманыннан калган һәйкәлләр бар. Хан шәһәре — Анадолуның иң борынгы шәһәрләреннән. Византия (Бизанс) заманында “Каккабокане”, госманлы дәверендә “Хан Барчунлу” дип аталган. Совет кешесе күзлегеннән караганда, Ханда яшәүчеләр чын төрекләр. Алар сәлҗүкләрдән килеп чыкканнар, ә моның белән, күргәнебезчә, һәрбер төрек тә горурлана алмый. Әмма Хан Караагач авылындагы халыкка соңгы сүзләр кагылмый. Аларның борынгы бабалары сәлҗүкләр күчмә тормыш алып барганнар, 1815 елда гына бер урында төпләнгәннәр. Хәйрия авылында яшәүчеләрнең бабалары кырым татарлары булып, алар Госманлы җиренә 1902 елда күченеп киләләр. 1874 елда солтан Абдулхәмит II

Кырымнан килгән татарларга үз җирләренең бер өлешен бүлеп бирә һәм Ылыҗабашы авылы барлыкка килә. Болгар регионнары булган Тырнов һәм Шумладан качкан төрекләр 1892 елда Исканкуйу авылына нигез салалар. Кадыкуйусу авылының тирән тарихы турында тирә-яктагы язылган ташлар сөйли. Анда яшәүчеләрнең буыннары — Анадолу җирләрен византиялеләр белән көрәшеп алучылар. XIX гасырның икенче яртысында Урта Азиядән күчеп килүчеләр Кайы авылын төзиләр. Көрхасан поселогының тарихы үзенең тамырлары белән 1200 елга барып тоташа. 1939 һәм 1950 елларда анда яшәүчеләрнең саны Болгариядән килгән мөһаҗирләр хисабына тулылана. Орхания авылында башта 7 йорт була, 1892 елда Румыниядән качкан кешеләр шунда урнашалар. Османия авылының килеп чыгышы турында ике риваять-юрама бар. Беренче риваять: авыл 1877 елда урыс-төрек сугышы вакытында Идел-Урал татарлары тарафыннан төзелгән. Мондый хәбәрне илчә идарәсендә алырга мөмкин. Бу сугышта татарлар күпләп төрек армиясе ягына күчәләр, сәбәбе билгеле — алар урыс колонизаторларының файдасына көрәшергә теләмиләр. Әмма анда яшәүчеләр үзләре авыл 1893 елда салынды, диләр. Печәнә авылы моннан 100-120 ел элек барлыкка килә. Садыроглу авылы 1950 елларда Бәлпынар авылыннан аерылып чыга. Соңрак аларга карачайлар һәм Румыния, Болгария эмигрантлары килеп кушыла. Сәетхәлимпатша авылына 1913 елда нигез салына, Румыния, Болгария, Грециядән киләләр, мөһаҗир-төрекмәннәр җыела. Сарыкафак авылының барлыкка килүен 1848 ел белән бәйләп күрсәтәләр. Анда чын төрек халкы яши. Язылыкайа авылында яшәүчеләр үзләренең килеп чыгышларын түбәндәгечә аңлаталар: 1883 елда Кавказдан качкан чиркәсләр, 1886 елда монда килеп урнашалар. Янтуган авылында төрекмәннәр өстенлек ала. Кырымның Күкташ авылы татарлары 1902 елда Йолдызөрән авылын төзиләр. 1894 елда румын төрекләре Заферхәмит авылына нигез салалар. 1920 елда аның халкы Болгария, Румыния, Кырымнан күчеп кайтучылар белән тулылана.

Чифтәләр илчәсе дә, гомумән, Искешәһәр вилаяте дә без караган мәсьәләдә башкалардан аерылмыйлар. Бөтен Төркия

буенча шундый ук күренеш. Идел-Урал регионыннан булган татарлар тагын Кутахья, Конья, Акшәһәр, Илгын, Измир вилаятьләрендә, шулай ук Истанбул һәм Әнкара шәһәрләрендә урнашалар. Төркиядә Кырым татарларын бүгенге көндә 5 миллионга якын дип әйтәләр. Төньяк-көнчыгыш районнарда нигездә Әзербайҗан һәм Төньяк Кавказдан килүчеләр урнашкан. “Чын әзербайҗан” шәһәрләре дә бар; мәсәлән, Ыгдыр шундыйлардан. XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасырның башында Госманлы дәүләте хәзерге Израильне хәтерләтә. Урыс-төрек сугышлары нәтиҗәсендә төрекләр күпләп Балканны ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Төньяк Кавказ һәм Урта Азиянең колонизацияләнүе бу регионнардан күп кенә кешеләрнең качуына сәбәп була. Рәсәйнең үзәк районнарындагы төркиләр дә, милли-дини изүгә чыдый алмыйча, Анадолуга бик күпләп күченәләр.

Иң кызыгы шунда ки, чуар, күп телле, төрле-төрле халык, Госманлы җиренә җыенып, тиздән бербөтен төрек милләтенә әверелә. Могҗизамы? Юк. Югары дәрәҗәгә, милләт дәрәҗәсенә күчү бөтен төрек этносының бөтен узган үсеше белән билгеләнгән иде. XX гасыр башында төрекләр уртак әдәби телгә ия булып, бер гомуми дәүләткә берләшәләр. Дифференциация вә интеграция мөнәсәбәтләре диалектикасы, эре этнослар үсешендәге бу капма-каршы процесслар көрәше тиздән төрекләрнең берләшүе һәм яңа дәүләт барлыкка килүе турында сөйли иде. Һәм чыннан да, 1923 елда Төркия җөмһүрияте барлыкка килә. Төрекләрнең берләшү тенденциясе, ниһаять, җиңүгә ирешә, әмма бик тар кысаларда, фәкать яңа дәүләтнең чикләрендә.

Тарихи закончалык тулы күләмдә үз хезмәтен башкара алмады. Аның сәбәпләре билгеле, алар 1914 елдан соң булган вакыйгаларга бәйле. Алар төрек тарихына кискен борылыш ясый. Госманлы җирләре басып алына, Рәсәй сугышта җиңелә һәм тиздән канга чума. Шушы чорда Кытайның да дәүләт төзелеше үзгәрә. Төркиләр Рәсәйдә большевиклар тарафыннан бүлгәләнәләр һәм башка илләрдәге кардәшләреннән генә түгел, ә бәлки бер-береннән дә изоляцияләнәләр. Алар этник-мәдәни үсештә артка алып ташланалар,

чөнки бүлү инде үлеп беткән кабилә (нәсел) үзенчәлекләре эзләре буенча алып барыла. Төрек этносын тәшкил итүче элементлар үзләре мөстәкыйль берлек дип игълан ителәләр. Аларның һәрберсенә аерым әлифба, аерым исем бирелә. Милли дәүләтчелек исә, аз хокуклы булуына да карамастан, бөтенесенә дә тәтеми. Аннан соң Кытайда да төрекләргә шундый ук мөнәсәбәт кабатлана. Нәтиҗәдә, этносның табигый үсеше бозыла. Төрекләр үзләре таралган мәйданда бербөтен милләт булып оеша алмыйлар. Этнос үзенчәлекле рәвештә берләшә — үзе яшәгән туфракларны берләштерү насыйп булмагач, ул туфраклардан вәкилләр уртак бер җиргә җыела. Гаспралының бөтен төрекләрне берләштерү хыялы тормышка аша, ләкин миниатюр күләмдә. Шулай итеп, XX гасырның беренче чирегендә гомуми төрек милләте оеша. Төрек телендә “төрки” дигән төшенчәнең булмавы юкка гына түгел, “төрек” дигән термин бөтен төрекләрне үз эченә ала. Мәсәлән, безне Төркиядә Казан яки кузәй төрекләре дип йөртәләр. Әрмәннәрнең дә барыбызны да төрекләр дип атавын билгеләп үтик. “Төркия җөмһүрияте” дигән исем, мәгънәсе буенча, урысның “Тюркская республика”сына тәңгәл килә. Урыс теленә “тюрк” һәм “турок” төшенчәләренең кайчан һәм кем тарафыннан кертелүе тарихына тукталмыйбыз инде. Бары тик шуны әйтеп үтәргә кирәк, асылда ул “бүлгәлә һәм хакимлек ит” сәясәтенең чагылышы булып тора. Тел чаралары аша шундый фикер үткәрелә ки, төрек, татар, казакъ, үзбәк — төрле милләтләр. Шулай итеп, төрек милләте — бөтен төркиләрнең берлеге, ә төрек теле — бөтен бүгенге көндә татар, казакъ, үзбәк һәм башка “телләр” буларак билгеле төрки диалектларының, төгәлрәк итеп әйткәндә, аларның иске вариантларының — иске татар, иске казакъ, иске үзбәк һ.б. синтезы. Шушы принципиаль нәтиҗәдән аңлашылганча, Төркиядә татарларның күпме булуы турындагы сорау төпле түгел. Сүз бары тик, нәкъ Израильдәге сәвит яһүдиләре кебек, күптән түгел шунда барып урнашкан һәм гомумтөрек байлыкларын үзләштереп өлгермәгән якташларыбызның саны турында гына булырга мөмкин. Сәвит иленнән киткән яһүдиләр дә беренче вакытта аерылып торалар икән. Ф. Хәкимҗанов китергән саннар

буенча, 1917 елга кадәр Анадолуга качкан татарларның күпчелеге этник төркем үзаңыннан арынып, гомумэтник үзаңны үзләштергән.

Төркиядә яшәүче татарларның тормышлары белән танышу, очрашу һәм сөйләшүләр шуны күрсәтә ки, аларны тел һәм мәдәният проблемалары борчымый. Алар бары тик Рәсәй төрекләре өчен генә хас. Төркиядә бу турыда белмиләр дә. Татар төрекләре төрек, ягъни ата-бабалары телендә сөйләшәләр, аларның гореф-гадәтләре буенча яшиләр. Төрек теле (укы: иске татар теле) — аларның туган теле. Соңгы елларда тарихи Ватаннары белән үзара бәйләнешләр киңәю йогынтысында татарлар үзләренең оешмаларын төзиләр. Безгә ике берләшмә билгеле. Истанбулда Идел-Урал төрекләренең мәдәният һәм ярдәмләшү җәмгыяте бар. Аны Синан әфәнде Отрав җитәкли. Оешма әгъзалары үзләренең төп бурычларын Татарстанга мөстәкыйльлек яулап алуда, анда яшәүче халыкның телен һәм мәдәниятен торгызуда һәрьяклап ярдәм итүдә күрәләр. Алар Татарстан Президентының Төркия җөмһүриятенә визитын тормышка ашыруда зур ярдәм күрсәттеләр. Рәсәй татарлары, ял көннәрендә бергә җыелып, үзләренең туган телләрендә сөйләшергә мөмкинлек тапканга шатланалар. Туган тел турында балаларына аз гына булса да мәгълүмат бирү өчен, аларны якшәмбе мәктәпләренә илтәләр. Туган тел моңнарын ишеткәч, анда җыелучы кешеләрнең күзләренә яшь тула... Менә шундый очрашулардан соң, чарасызлыктан, көчсезлектән күңелдә авыр тәэсир кала. Милләтебезнең урыс, христиан массасында эреп баруын күрү бик кызганыч иң.

Синан әфәнде Отрав оешмасының җыелышлары иң якын туганнар җыелган зур бер бәйрәмне хәтерләтәләр. Анда Рәсәйдәге татарларның тормышы турындагы хәбәрләр тыңлана. Чәй янында сүз, нигездә, экономик проблемалар турында бара. Тарихи Ватан белән элемтәләрне ничек итеп киңәйтергә? Татарстанда товарлар белән сату-алуны ничек җайга салырга? Базар мөнәсәбәтләренә күчеп барган җөмһүрияткә чит илләрдән акча кирәк. Анда күп акчалар тотып тәвәккәлләргә буламы соң? Татар төрекләрен бүгенге көндә менә шундый сораулар борчый. Шушы проблемаларны

чишү өчен Төркиядәге татарларның мәркәзе булган Искешәһәрдә 1992 елның 2 январенда Казан Мәдәният җәмгыяте төзелә. Аңа нигез салучылар булып Чифтәләр илчәсенең Османия авылы кешеләре санала.

Авыл картларының сөйләүләре буенча, аларның әти-бабалары Анадолуга Урал якларыннан килеп урнашканнар. Урал (Җаек) елгасының исеме белән бәйләнгән күп кенә фамилияләр моны исбатлыйлар — “CAYIK”, “CAYIKLI”, “CAYIKDAN” һ.б. Авыл урнашкан урын Ырынбур панорамасын хәтерләтә. Авыл калкулыкта ята, шуңа күрә аның элекке исеме дә “Куруһүйүк”, ягъни “Коры калкулык” дип атала. Табигать шартлары да бик охшаш. Җәй көне монда коры һәм эссе, кышларын исә, бик кырыс, суык була. Яшьләр авылдан шәһәргә күчеп китә. Илчәдә беренчеләрдән булып ачылган башлангыч мәктәптә бары тик ике укытучы гына эшли. Статистика буенча, 1985 елда авылда 249 кеше яшәгән, бүгенге көндә аннан да азрак.

Бик матур мәчет эшли. Өйләр тыштан ялтырамый, әмма эчләре гүзәл. Авыл үзенең төрекмәннәрдә булмаган мунчалары белән танылган була. Хәзерге вакытта бер генә мунча калган. Татар булган җирдә ызгыш-талаш. Авылдашлар ике төркемгә бүленгән — хәзерге мухтар (авыл башлыгы) Йөзҗан Яфай яклы кешеләр һәм аңа каршылар.

Казан җәмгыяте эчендә дә төрле каршылыклар бар. Турыдан-туры күрешүләр күрсәткәнчә, бу җәмгыятьтә иҗтимагый-сәяси карашлары буенча якын кешеләр җыелган. Күпчелек татарлар бу берләшмәләр турында беләләр, ләкин аларның эшчәнлегендә катнашмыйлар. Төркиядә милли проблема юк, бөтенләй башка тел гаиләсенә караган көрдләр һәм төрек массасы арасында аңлашылмаучанлык кына бар. Икътисади һәм иҗтимагый-сәяси проблемаларны хәл итү өчен гражданнар анда төрле оешмалар төзиләр. Татарлардан чыккан кешеләр төрле сәяси партияләрдә торалар, күп очракларда алар капма-каршы максатны күздә тоталар.

Искешәһәрдәге киемнәр кибетенең хуҗасы Абдулла Яваш миңа бик кызыклы тарих сөйләде. 1982 елда аның этисе ниндидер могҗиза ярдәмендә СССРга килеп чыга.

Ырынбур өлкәсендәге туган авылын эзләп таба, анда кардәшләре белән очраша. Шул хәлләрдән соң, авылда КГБ хезмәткәрләре еш күренә башлый. Алар Абдулланың туганнарын милләтчелектә, төркичелектә, төрек бозкуртлары ("күк бүреләр") белән элемтәләр урнаштыруда, Ырынбурны Төркиягә кушу планнары эшләүдә гаеплиләр. Иң кызыгы шунда ки, төрекләрнең яшерен полициясе — МИТ тарафыннан Абдулланың әтисе дә эзәрлекләнә. "Күләгә кебек артыннан йөриләр иде", — ди ул бу хакта исенә төшереп.

— Әллә сездә дә милли билгеләр буенча эзәрлекләүләр бармы? — дип сорамыйча булдыра алмадым. Чыннан да, бу елларда КПСС Төркия коммунистларын бик юмарт финанслый, шул акчага алар төрле тәртипсезлекләр оештыралар, шәһәр һәм авылларда башка караштa торган кешеләрне кыйныйлар. Илдә курку мохите тудырыла. Мәскәүдә партия җитәкчеләре властька коммунистлар килүен Һәм Төркиянең "социалистик лагерьга" кушылуын көттеләр. Аңлашыла ки, СССР белән һәр элемтә бу болганчык елларда төрек властьларында шик тудыра. 30 нчы еллар ахырыннан Казан төрекләре Союздагы туганнары белән хат алышу мөмкинлегеннән дә мәхрүм ителәләр.

Бүген инде мондый коточкыч нәрсәләр артта калды. Төркиядәге татарлар өчен бернинди үзенчәлекле проблемалар юк. Алар үзләрен төрек халкының аерылмас бер өлеше итеп карап, аның шатлыклары һәм мәшәкатьләре белән яшиләр. Искешәһәрдә канализация системасы үткәрә башладылар, элек ул анда юк иде. Шәһәр урамнарындагы күп урыннар казылу уңайсызлыклар тудыра, әлбәттә. Бүген гаиләләрдә шул турыда сөйләшүләр өстенлек алып тора...

*1994*

# МӘЧЕТЛӘР НИГӘ БУШ?

Дәүләт халыкка дин иреге бирде. Барлык татар авылларында диярлек мәчетләр калыкты. Авылларыбыз ямьләнеп, нурланып китте. Әмма, ни кызганыч, күп вакыт мәчетләр буш. Дөрес, елга ике тапкыр — Рамазан һәм Корбан бәйрәмнәренә — Аллаһы йортларына халык җыела.

Динебез хәле турында уйлансак, шуны күрәбез — кагыйдә буларак, дингә олы яшьтәге кешеләр бирелгән. Әгәр берәрсеннән:

— Намаз укыйсыңмы? — дип сорасаң,

— Нәрсә, мин шундый карт күренәмме инде, — дигән җавап ишетәсең. Ягъни, безнең аңыбызда мөселманнарга хас таләпләрне үтәү картлык белән бәйләнгән.

Бүгенгә безнең яшьләр йөрәгенә ислам руханилары ачкыч табалмады. Татар егетләре-кызлары хәзер төрле, безгә ят секталарга керә, хәтта дин аферистлары йогынтысына да бирелә. Алар кайда гына юк — Церковь Христада да, Белое Братствода да, бахаистлар, баптистлар һ.б. Һ.б. арасында да. Бу коточкыч хәл, бу фаҗига. Сәбәбе? Аз дигәндә алар өчәү. Беренчесе, Совет чорында яшьләр мәчеттән махсус читләштерелде. Мәчеткә курыкмыйча картлар гына йөри алды. Икенчесе, шул ук Совет чорында ислам диненә коточкыч консерватив төсмер бирелде. Әллә нинди, дин белән һич бәйләнеше булмаган тыюлар кертелде. Мәсәлән, элек партия райкомы секретаре булып эшләгән муллаларыбыз мәчеткә хатын-кызны якын китермәскә тырышалар, ир-атның башында түбәтәй булуны таләп итәләр һ.б. Ул ярамый, бу гөнаһ, тегесе өчен тәмугъта янасыз. Тыю, куркыту, янау. Ягъни, бүгенге динебез фәкать куркуга корылган бер идеологиягә әверелде. Ә читтән килгән акыллы миссионерлар ничек? Аларның беренче сүзләре: “Бог Вас любит”. Без барыбыз да бит җылы сүзгә, сөюгә мохтаҗ! Яшьләрнең бу секталарга тартылуы бер дә гаҗәп түгел. Өченчесе. Бүгенге индустриаль шәһәрдә яшәгән, ана телен дә ипи-тозлык кына белгән татар баласы ислам гыйбадәтен ничек үзләштерсен? Элек дини йолалар буыннан-буынга автоматик рәвештә бирелеп килгән. Геннар кебек. 1917 елны бу процесс өзелә.

Безнең әти-әниләребез динсезлек заманында җитеште. Дини белемне алар бирә алмады. Әйе, шәһәрләрдә дә мәчетләр күп. Анда барып укырга була. Әмма мәчеткә бик озак йөрергә кирәк шул. Чөнки намазларга өйрәнер өчен башта гарәп әлифбасын үзләштерү сорала. Аннары аз гына булса да, гарәп телен өйрәнәсе бар. Коръән дә ятлана. Моңа аз дигәндә 2-3 ел кирәк. Бу артык кылану түгелме соң? Бүгенге динамик тормышта һәммәбез дә намаз кыларга өйрәнер өчен генә бу кадәр вакыт бирә алабызмы? Ә безнең күршеләребез христианнарда ничек соң? Барлык христиан халыклары гыйбадәтне үз телләрендә кыла. Хәтта бик аз санда булган керәшеннәр дә бездән күпкә бәхетле. Казанда, мәсәлән, аларга аерым бер чиркәү бирелде. Алар анда рәхәтләнеп татарча гыйбадәт кылалар. Әлбәттә, мине күпләр гаепләр, әмма мин бер нәрсәне һич аңлый алмыйм — Аллаһы Тәгалә гарәпчә генә беләмени? Шул ук догаларны рәхәтләнеп татар телендә укысак, ягъни Ходайга үз телебездә мөрәҗәгать итсәк гөнаһ буламы? Аннары тагын бер нәрсәне күздән качырмыйк. Егерме беренче гасыр бусагасында, космоска очып, фәнни-техник казанышлар киң кулланылган чорда, башында акылы булган кешене чит бер телдә өзекләр ятлатып, маймыл кебек борын астыннан мыгырдату мөмкинме?

Нигә мәчетләр буш? Нигә анда картлар гына очрый? Безнең дин әһелләребез бу мәсьәләләр турында да уйлансын иде. Яшьләрне сүгеп кенә чынбарлык үзгәрми. Дингә халыкның өмете бик зур. Ул фидакарь рәвештә, соңгы акчасына йөзләгән мәчетне торгызды. Әмма җәмгыятебезнең бүгенге иҗтимагый тормышында ислам dиненең роле юк диярлек. Бу ник дин белгечләрен борчымый? Алма пеш, авызга төш дип көтәргә түгел. Киресенчә, руханилар үзләре халыкка таба хәрәкәт итәргә тиеш. Кечкенә кенә мисал. Яшьләр өйләнешә. Барысы да матур киенгән. Йорт-җир ялтырый. Һәркем шат йөзле. Шушы олы бәйрәмдә шәлтерәгән бер бабай килеп никах укый. Ә бит никах зур, мәһабәт мәчеттә кылынса, ул истәлекле, күркәм бер вакыйгага әверелер иде. Юк, шуны да мәчет хуҗалары оештыра алмый...

Бүген дин үзенең изге бурычын үтәми. Җәмгыятьтә

әхлаксызлык югары ноктасына җитте. Эчкечелек, җинаятьчелек, фәхишәлек чәчәк аталар. Аларны дәүләт кенә җиңәлми. Чөнки бу проблемалар инануга, иманга килеп тоташа.

Бөтен төрки халыклар арасында татарлар һәрвакыт иң алдынгы, иң интеллектуаль халык буларак танылган. Заманында суфичылык та, җәдидчелек тә бездән туган. Бәлки, бүген дә искергән, катып беткән карашлардан арынып, динебезгә җитди үзгәрешләр кертергәдәр? Ислам беркайчан да, беркайда да үзгәрмәячәк, имеш. Бу сүзләр белән һич килешеп булмый. Исламның һәр заманга һәм һәр халыкның үзенә генә хас шәкеле булырга тиеш. Югыйсә, татарлар өчен Мөхәммәт пәйгамбәр тәгълимате ата-бабаларыбызның дине турындагы бер хәтер генә булып калачак...

*1995*

# ЗӘЛИДӘ УЕНЫ

Уен дигәч тә, гаҗәпләнмәгез. Уен — гаять мөһим нәрсә, мәдәниятнең бер өлеше ул. Тел кеше тормышы белән бәйле төрле өлкәләрдә яши: эш җирендә, мәктәптә, базарда, хәтта безнең исем-фамилияләрдә һәм ... уен-көлкедә. Элек-электән безнең халык тырышып эшләгән һәм матур иттереп күңел ача белгән. Аулак өйләр, елга буйлары, табигатьнең ямьле аланнары уен-көлке, җыр-бию урыны булган.

Яшьләрдә милли мәдәнияткә кызыксыну уятуны күздә тотып, телевизион тапшырулар остасы Э.Хамматова белән бергә өч-дүрт тапкыр Зәлидә уенын оештырып үткәрдек. Зәлидә — үзебезнең милли уеныбыз ул, гади дә, кызык та. Бернинди махсус җайланмалар, чыгымнар таләп итми ул. Аны мәктәпләрдә, авыл клубларында, инде әйткәнемчә, табигать кочагында да оештырырга мөмкин.

Башта яшьләр бии. Музыка тәмамлангач, алар китеп утырышалар. Ике алып баручы уен тәкъдим итеп, зал уртасына иң тәвәккәл 10 егет-кызны чакыра. Залга 9 урындык чыгарыла һәм түгәрәкләп төзеп куела. Алып баручылар уен кагыйдәләрен аңлаталар. Алар гади. Яшьләр

кулларын тотынып әйләнеп йөреп, татар җырын башкаралар. Музыка туктауга, җитез рәвештә урындыкларга утырышалар. Берәүгә урындык җитми. Аңа җәза-сорау бирелә. Сораулар татар мәдәниятенә һәм тарихына кагыла. Мәсәлән, Тукайның “Туган телен” сөйләргә һ.б. Сорауга җавап бирелмәсә, уенчының аклану мөмкинлеге бар — ул кызыклы бер нәрсә башкарырга тиеш. Бу нәрсә җыр, бию, мәзәк сөйләү һ.б. булырга мөмкин. Бу аклану чарасын һәр уенчы хәзерләп килә. Сорауга җавабы яисә берәр сәләте белән уенчы тамашачыларга ошаса, аңа бүләк бирелә. Шулай итеп, бер уенчы уеннан төшеп кала. Урындыклар да 8 генә калдырыла. Уен дәвам итә. Һәрвакыт урынлы булган уенчы, сорауга җавап бирәлсә, җиңүче була. Аңа иң саллы бүләк тапшырыла.

Бу уенда зал тирәсендә утырышкан тамашачылар да актив катнаша, чөнки җавапсыз калган сорауларга җавап тамашачылардан алына. Һәм андыйларга шулай ук бүләк тапшырыла.

Без биргән кайбер сорауларны да китерәм.

*Казан Кремлендә Кол Шәриф мәчете төзелде. Кем ул Кол Шәриф?*

*Төркиядә яшәп иҗат иткән бөек татар язучысы кем? (Гаяз Исхакый)*

*Ирекнең, азатлыкның символы буларак табигатьтә кайсы хайванны күрсәтергә була? (Бүре)*

*Төркиянең башкаласы кайсы шәһәр? (Әнкара)*

*Татар һәм фин телләре арасында нинди бәйләнеш бар? (Алар икесе дә Урал-Алтай телләре гаиләсенә керә)*

*Казан шәһәрен үз иткән, аны олылаган тугандаш чуаш халкы язучысы кем? (Педер Хузангай)*

*Татарстанның иң бөек тавы исеме ничек? Республиканың иң югары ноктасы ничә метр? (Азнакай районындагы Чатыртау. Ул диңгездән 367 м).*

*Большевиклар революциясенә кадәр татар мәдәни тормышы кайнаган шәһәрләрне беләсезме? (Оренбург, Троицки, Уфа, Әстерхан һ.б.)*

*Нәүрүз бәйрәмен беләсез. Бу тамашада Нәүрүз бикә Кыш*

*бабай белән көрәшә. Ник Нәүрүз кызы һәрвакыт өстен чыга?*

*Тукайның мәхәббәте кем булган, ягъни Тукай яратып йөргән кызның исеме ничек? (Зәйтүнә)*

*Белүебезчә, Мөхәммәт пәйгамбәр дә реаль шәхес булган. Аның әтисенең һәм әнисенең исемнәре ничек? (Габдулла, Әминә)*

*Исламга кадәр безнең ата-бабаларыбыз тәңречелек динендә булган. Бу диннең нигезе ниләрдән гыйбарәт? (Табигатькә, ягъни күк, кояш, ай һәм җир-суга табыну. Вафат булган ата-бабалар рухларын олылау)*

*Казан ханлыгын төзегән, аны яшәтеп җибәргән татар ханы кем? (Олуг Мөхәммәт)*

*Казан ханлыгы ничәнче елда оешкан? (1439)*

*1996*

## ТӨРЕК ТАТАРГА ЯРДӘМ ИТӘРМЕ?

Татар өмет белән яши. 1552 елдан соң нинди генә дәһшәтләр кичерсә дә, ул аны җуймады. Азатлыгын, бәхетле, ирекле тормышын кайтару өмете аңа яшәү көче бирде. Рус империясе татарны җиңде, таптады, изде. Әмма дөньяда төрек кардәшләренең көчле дәүләте бар иде. Гасырлар буе татар төрек солтаны ярдәм итәр дип ышанды, бу ярдәмне көтте. Ләкин еллар үтте. Госманлылар йолдызының яктылыгы да кими барды.

Ниһаять, XX гасыр ахырында төрек яңадан аякка басты, чәчәк атып яши башлады. Татар да кузгалды, азатлык дауларга кереште. Элеккечә үк көрәш тигез түгел, искиткеч авыр. Кардәшләренең ярдәменә ул яңадан да мохтаҗ.

Чикләр ачылгач, Казанда беренче төрекләрне күреп, без балаларча сөендек. Төрекләр килде! Тел вә дин кардәшләребез милләтебезгә көч өстәрләр, телебезне, мәдәниятебезне торгызуда ярдәм күрсәтерләр дип шатландык. Кыйналып, кимсетелеп килгән малай янына аның көчле абыйсы килеп баскан кебек булды. Абый яклар, башкалардан рәнҗеттермәс!

Менә “Заман” газетасы вәкилләре дә “Татарстан-Төркия” дуслык җәмгыятенең ишеген шакыды. Хуш килдегез! Өч егетнең өч көнлек туристик визасы бар. Казанда аларның

башка һичбер нәрсәләре юк. Алар биредә яңа басма чыгарырга килде. Бөтен эшләремне ташлап, һәркөн армый-талмый егетләрнең миллионлаган проблемаларын хәл итеп йөрибез. Аларны бер генә сәгатькә дә калдырырга ярамый, чөнки төрекләр — чит илдә, монда хакимлек иткән урыс телен дә белмиләр. Шуңа күрә турыдан-туры газета эшләрен генә түгел, аларның күпсанлы шәхси, көнкүреш мәсьәләләрен дә хәл итәргә туры килә. Хәтта төннәрен дә, кирәк булганда, торып йөгерәм. “Заман”га баглаган зур өмет миңа искиткеч гайрәт бирә. Халкыма бу басма бик кирәк. Ярты ел эчендә гаять авыр эш башкарыла: “Заман”ның Татарстан вәкиллегенә офис булдырыла, даими визалар мәсьәләсе хәл ителә, бөтен кирәкле хәер-фатихалар алына, яңа дуслар эзләп табыла, басманың нигезенә дистәләгән татар язучысының, галименең, журналистының хезмәттәшлек вәгъдәсе салына.

Шундый ук ярдәмне җәмгыятебез Казандагы Эртугрул Гази исемендәге төрек-татар лицеена да күрсәтә. Сер түгел, күп очракларда янгын командасы кебек чабарга туры килде. Әле дә хәтеремдә, узган җәй башында яныма кайгылы кыяфәттә ширкәт вәкиле Камил Демиркая белән лицей директоры ярдәмчесе Хәсән Октан килеп утырды. Хәлләре, чыннан да, бик мөшкел. Ниятләре — кырыклап укучыга Төркияне күрсәтү. Иртәгә китәргә, очкычка билетлар кулда. Әмма бер генә баланың да чит илгә чыгар өчен документы әзер түгел. Гаеп төрекләрнең үзләрендә — ОВИР сораган кәгазьләрне үз вакытында тапшырмаганнар. Ә хәзер инде соң.

— Фирдүс бәй, күпләргә мөрәҗәгать иттек, булмады, ярдәм ит, зинһар, — диделәр. Берничә сәгать эчендә барысы да булдырылды. Бу эшне ничек ерып чыктым, бүген дә аңламыйм. Ниндидер илаһи көч килде үземә.

Инде шөкер. “Заман” да чыга башлады, төрек-татар лицее дә эшләп килә, андый лицейлар тагын берничә шәһәрдә ачылды. Төрекләр биредә. Әмма ни гаҗәп, төрекләр эшчәнлегенең милләтебез яшәешенә уңай йогынтысы әлләни сизелмәде. Халкыбызга без зарыгып көткән яңа рухи көч өстәлмәде. Милли мәктәпне торгызу, мәдәни байлыкларыбызны кайтару, телебезне үстерү мәсьәләләре аларны аз кызыксындыра. Бихисап хезмәт түгеп, йөрәгемнең бер

өлешен төрекләргә аерып биреп, шундый нәтиҗәгә килү минем өчен фаҗига кебек булды.

Төрекләр монда булганда җөмһүриятебез гаять авыр көннәр кичерде. Рәсәй матбугаты тормышыбыз турында фәкать ялган гына биреп килде. Информацион блокадада калган айларда “Заман”ның бөтен дөньяга җәелгән мәгълүмат тарату челтәре булуын белеп, без Президент матбугат үзәге җитәкчесе Әнәс абый Хәсәнов белән Төркиянең Татарстандагы вәкиле Муаммәр Моратка ярдәм сорап мөрәҗәгать иттек. Әмма аның тарафыннан Татарстан хакында бер генә материал да җибәрелмәде. Мин айлар буе моның сәбәпләрен аңламыйча йөрдем. Һәм, ниһаять, Төркиядә булып кайткач, күзләрем ачылды, барысы да аңлашыла башлады.

Татарстанда берничә лицей ачучылар һәм газета нәшер итүчеләр Төркиянең бер төркем, бер катлау вәкилләре генә булып чыктылар. Заманчылар яисә фәйтуллаһчылар дип атыйлар аларны. Аларның хоҗалары (остазлары) үзләренә күркәм, изге бурыч йөкләнгәннәр: төрек милләтенең Көнбатышка ияреп әхлакый таркалуын туктату, яшьләрне динебез таләпләре буенча тәрбияләү. Төркия өчен бу мәсьәлә дөрестән дә актуаль. Телевидениедә, матбугатта бозыклык күп. Хатын-кыз киемнәре артык ачык, вульгар. Олысы-кечесе, ире-хатыны тәмәке тарта. Мәсәлән, шәһәрара автобусларда төтенгә түзеп булмый. Милләтнең рухын савыктыру идеясе төрек җәмгыятендә киң яклау таба, байлар исә бу эшкә акчаларын кызганмый. Бүгенге көндә заманчылар Төркиядә генә түгел,Урта Азия республикаларында да актив эшлиләр.

Заманчылар даирәсенең Эртугрул Гази ширкәте Казанда, Чаллыда, Түбән Кама вә Әлмәттә дә төрек-татар лицейлары булдырды. Әйткәнемчә, лицейларның төп максаты — яшьләрне Ислам канаты астына сыендыру. Әмма Төркия вә шулай ук Урта Азия белән Татарстан арасы — җир белән күк арасы. Төрекләр, әзариләр, үзбәкләр һ.б. үз дәүләтләре белән, үз телләрендә, үз милли мохитләрендә көн күрәләр. Бездә исә яшьләрнең күпчелеге ана телен белми. Мин Казан каласында 1979 елдан бирле яшәп урамнарда, трамвай-

троллейбусларда татар балаларының үзара ана телендә аралашуына һич шаһит булмадым. Балаларыбыз рус җырын җырлап, рус шигырен ятлап, рус тарихын өйрәнеп үсәләр.

Төркиядән килүчеләр сукыр түгел — моны бик тиз күрделәр. Ләкин хуҗалары биргән генераль стратегия какшамады:

— Безгә милләт, тел мөһим түгел, кеше мөселман гына булсын, — диделәр.

Кулымда Казан лицееның реклама проспекты. Билгеле инде, ул русча язылган, бер кәлимә татарчасы юк. “Беренче елны, әзерлек сыйныфында, инглиз (18 сәгать), төрек (8 сәгать) һәм татар (2 сәгать) теле укытыла”, — диелгән анда. Күргәнебезчә, татар теленең монда абруе юк. Бәлки, киләчәк сыйныфларда хәл үзгәрер? Юк шул: “Соңрак математика, физика, химия, биология кебек фәннәр инглизчә, тарих, география, психология һ.б. төрекчә бирелә”. Ягъни, укучы үзаңын формалаштыруда төп роль уйнаган төгәл вә табигать фәннәре инглизчә укытыла, һәр мәктәптә икенче пландарак торган инсани фәннәр төрекчә, ә татар теленә — кәҗә тоягы. Нәтиҗәсе күз алдында — лицей укучылары үзара русча гына сөйләшә.

Үткән елны Эртугрул Гази ширкәте Чабаксарда да лицей ачты, уйлары якын киләчәктә эшне саф рус шәһәрләренә җәелдерү. Беренче карашка шатлыклы хәл: Төркиягә, Америкага бару, инглиз телендә уку белән кызыксындырып, русны Исламга якынайту, әгәр килеп чыкса, намазга да бастыру. Димәк, заманчыларның максатлары зурдан — рустан мөселман ясау! Кызганыч, бу идея, минемчә, буш хыял. Реалистларча, җиргә нык басып уйлыйк әле. Нәрсә ул дин? Нигә бәйле? Кешегә иман ничек сеңә? Дин — рухи тормышыбызның бер өлеше ул. Җәмгыятьтә аның билгеле урыны бар — әхлакый сәламәтлекне саклау. Нинди дин тотуы кешенең нинди дөнья вәкиле булуы, аның нинди телдә сөйләшүе, тирә-якта нинди мохит хөкем сөрүенә бәйле. Ягъни авылда — татар мохитендә туган, үз ана телендә сөйләшкән бала, “әни”, “әти” сүзләре белән беррәттән, “бисмилла” ди, Кострома Ванькасы “боже мой” ди, ә Казанда татардан туган рус малае — динсез. Һәм төрек кардәш-

ләребезнең төп хатасы — динне рухи тормышның башка компонентларыннан аерып алып абсолютка әвереләдерү. Кеше инанган динне ул кешенең үзен тулаем үзгәртмичә алыштырып булмый! Ат арбасы самолет моторы куеп кына оча башламый әле. Бөтен тирә-якларында христианлык хакимлек иткәндә, руслар чиркәүләрен сүтеп мәчет салырлармы? 140 миллион русның 10 кешесен иманга китердек, дип шапырыну җүләрлек түгелме? Рустан мөселман ясар өчен аны, ким дигәндә, Төркиягә күчереп төрекләштерергә, ягъни башка мохиткә чумдырып, яңадан тудырырга кирәк. Телибезме-теләмибезме, дин телгә, бөтен мәдәнияткә бәйләнгән. Алар бер-береннән аерылгысыз. Билгеле бит инде, татар милли мәдәниятен Исламнан аерып булмый, шулай ук "өлкән брат"ның мәдәнияте дә христианлыктан башка күз алдына килми.

1917 елга кадәр татар үз дөньясы белән яшәде. Ул дөньяның чикләрен туган авылы били иде. Авылда татарның үз мохите, үз мәдәнияте булды. Туган як чишмәләренең суын эчеп, елга буенда кичке уеннарда җырлап-биеп, милли рух сеңдереп үскән татарны поплар христианлыкка күчерә алмады. Чөнки соң иде инде. Бу мохиттә формалашкан кешене һич үзгәртеп булмый, аны үтерүе җиңелрәк.

Даһи Ленин асмады да, кисмәде дә, бәкеләрдә батырып вакытын да уздырмады. Ләкин, ни гаҗәп, патша миссионерлары гасырлар буе ирешмәгәнне нибарасы ике-өч дистә елда башкарды. Чөнки ул, заманчылардан аермалы буларак, олы эшкә керешкәнче, күп еллар буе эзләндеуйланды. Ниһаять, аңлады: татарны (һәм башка милләтләрне) бетереп, соры пролетариат массасына кушу өчен башта телне вә мәдәниятне бетерергә кирәк. Һәм дөрестән дә, телен һәм үз-үзенең йөзен югалтып, татар динсез калды.

1552 елдан килгән бабаларыбызны чукындыру тарихын 3 этапка бүләргә була. Беренче этапта — мәсҗетләрне җимерү һәм турыдан-туры көчләү. Аксак Каратун (Лука Канашевич) үзе генә 418 мәсҗетне вәхшиләрчә тармар иттерә. Пугачев сугышыннан соң әби патша татарларга мәсҗет төзергә һәм мәдрәсә ачарга рөхсәт бирә. Шул ук вакытта мөселманнарга төрле, хәтта башка сыймый торган салымнар (мәсәлән, кара

чәч өчен) салалар, ягъни икътисади яктан мәҗбүр итәләр. Нәкъ бу чорда татарлар күпләп Урал якларына күченәләр һәм башкорт сословиесенә язылалар, чөнки русның башкортка мөгамәләсе йомшаграк була. Бу ике этап XVI-XIX гасырларны үз эченә ала вә көткән нәтиҗә бирми. Һәм, ниһаять, мәйданга Каюм Насыйрилар чыга. Танылган рус миссионерларының большевиклар революциясе алдыннан басылган хезмәтләрендә самодержавиенең төп ялгышы ачык күрсәтелә инде — татарны христианлаштыру өчен аның диненә турыдан-туры бәрелү мәгънәсез, башта аны милләт буларак юк итәргә кирәк. Патша өстәленә конкрет тәкъдимнәр ята: татар балаларын мөмкин булган кадәр рус телендә укытырга, бу халыкның әлифбасын рус теленә яраклаштырып үзгәртергә, гомумән, милли мәдәниятен корытырга. Без һаман Каюм Насыйрины мактыйбыз, аңа каршы чыккан муллаларны томана, фанатиклар дип яманлыйбыз. Әмма ул томана фанатиклар бездән күпкә акыллырак булган түгелме соң? Алар интуитив сизгән — Каюм Насыйри, татар балаларын русча укытып, Исламның тамырын кисә.

Шулай итеп, Ленин, Сталин, Брежневлар "Америка ачмый", фәкать самодержавие миссионерларының тәкъдимнәрен генә тормышка ашыра һәм искиткеч уңышларга ирешә. Манкортлар бүген "Церковь Христа"да, "Дух жизни" чиркәвендә, "Белое братство"да, төрле харизматлар-бахаистлар арасында. Авылдан килгән татар малае гына мәсҗеткә сәдака кертә...

Димәк, заманчыларның Төркия шартларында эшләнгән методикасы безнең үзенчәлекне исәпкә алмый. Бинаның беренче катын кормыйча икенчесен салып булмаган кебек, Казан манкортыннан да, туган телен өйрәнмичә, 3-4 елда мөселман ясап булмый. Мөселманлыкны ана сөте белән, ана сүзе белән генә тәрбияләргә мөмкин. Шулай бер абыстай, ике кызга дин сабаклары бирәм, дип сөйләнде. Көннәрнең берендә мини-итәкле кызлар озын ялангач ботларын кояшта ялтыратып, хихылдашып абыстайдан кайталар. Гаҗәпләнеп уйга калдым. Намаз укыйлар, имеш...

Казанның Шамил Усманов урамындагы төрек лицее искә төшү белән, авызын ачса үпкәсе күренгән татарым күз

алдына килеп баса. Фидакарь галимнәребез югары уку йортларында татар телендә укытырга теләп азапланалар, китап-әсбаплар язалар, әмма аларны нәшер итәргә акчалары юк. Балалар бакчаларына матур бизәлгән татар китаплары кирәк. Республика телевидениесе татар кинолары, мультфильмнары турында хыяллана...

Төрекнең ярдәменә татар бүген бик мохтаҗ. Әмма американ колледжының пародиясен тудырган "Заман" даирәсе вәкилләренең үз уйлары уй. Пародия (уңышсыз ияргү) дим, чөнки бу лицейны танылган академигыбыз Мирза Мәхмүтов булдырган чын американ колледжы белән чагыштырып та булмый. Мирза абыйда укыту сыйфаты күпкә өстен. Америкадан килгән укытучылар, океан артында стажировкалар һ.б.

Мәкаләмне өмет сүзеннән башладым. Өзмик өметебезне. Төркия — зур ил. Анда төрле карашлы кешеләр, төрле даирәләр...

*1995*

# КАЗАННЫ ЯУЛАСАК — ЯШИБЕЗ, ЮКСА — БЕТӘБЕЗ!

"Төрек татарга ярдәм итәрме?" дигән мәкаләне берәүләр сүкте, икенчеләр авторга рәхмәт әйтте. Кайбер фикерләрне кабул итмәүчеләр бәхәсләште. Аяз көн кебек ачык мәсьәлә генә тыныч кабул ителәдер. Ә инде берәр четерекле проблеманы күтәрсәң, бигрәк тә кайберәүләрнең мәнфәгатьләренә кагылсаң, тавыш-гауга көт тә тор. Ни генә булмасын, мәкалә укучыны уйландырды бугай. Тик фәйтуллаһчылар үзләре генә берни аңламадылар, бәлки аңларга теләмәделәр. Алар ягыннан фәкать үпкә һәм янаулар ишетелде. Соңгысын һич көтмәгән идем. Бездә бит: "Кунак булсаң — тыйнак бул", — диләр... Үзләренең җавап сүзләрендә алар бик примитив юлга бастылар. Янәсе, "Татарстан — Төркия" җәмгыяте президенты татар-төрек дуслыгына каршы! Бу яла аларның вөҗданында калсын! Мәкаләне игътибар белән укучылар мондый нәтиҗәгә һич килмәсләр.

Татар зыялылары “Шәһри Казан” газетасында басылган “Гап-гади фашизм” дигән язмамны хәтерлиләрдер. Нәкъ Казан уртасында, Ленин урамындагы Пассаж бинасын әйләндереп алган коймада берничә ай төрек кардәшләребезгә каршы фашистик өндәүләр урын алып торды. “Убей турка”, “Смерть туркам” кебек язулар кызыл буяу белән мул итеп, метрлы хәрефләр белән язылган иде. Аларны күпләр укыды, әмма битараф калды. “Шәһри Казан” редакциясенә, халык депутаты Фәндәс абый Сафиуллинга рәхмәт. Бергәләп бу вәхшилеккә чик куйдык...

Милли басмабызда урын алган вә күп шау-шу тудырган күләмле мәкаләм татар-төрек мөнәсәбәтенә кагылып кына үтә. Аның төп эчтәлеге — татар теленең аяныч язмышы хакында. Ана телен милләтебезнең киләчәге — яшьләрнең абсолют күпчелеге белми. Моны танырга мәҗбүрбез. Әйе, авыл балалары белә. Алар туган телдә сабак ала. Әмма бүген авыл мәктәпләре буш диярлек. Аларда кагыйдә буларак берничә бала укый. Заманалар үзгәрде. Татарлар бүген зур шәһәрләрдә күпләп яши. Һәм милләтебезнең язмышы Казан, Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Әлмәт, Яшел Алан кебек шәһәрләрнең мәктәпләренә бәйле. Аларда милләттәшләребезнең меңләгән балалары.

Мәгълүм ки, баланың аңы, кем булып җитешүе турыдан-туры аның белем алган теленә бәйле. Тагын да гадирәк итеп әйткәндә, дәресләр кайсы телдә бирелүе, баланың кем җырларын җырлавы, нинди телдә шигырьләр сөйләве мөһим. Мәктәпләрдә, лицейларда, махсус һәм югары уку йортларында ана телендә белем алучылар саны үскән саен милләтебезне саклап калу мөмкинлеге арта. Шөкер, моны татар зыялылары беркайчан да онытмады һәм соңгы 5-10 елда шәһәрдәге һәр уку йорты, һәр дәрес, һәр бала өчен көрәш башланды. Шул исәптән, Татарстанда заманчылар ачкан берничә лицейның эшчәнлеген дә без битараф рәвештә күзәтә алмыйбыз. Алар егетләребезнең иң өметлеләрен, иң сәләтлеләрен чүпләп җыялар. Вә ни кызганыч, аларны инглиз телендә генә укытып, татарны киләчәктә милләте өчен хезмәт итәрлек язучылар, галимнәр, дәүләт эшлеклеләреннән, ягъни Габдулла Тукай, Шиһабетдин Мәрҗани,

Садри Максуди кебек олы шәхесләрдән мәхрүм итәләр. Лицейга кабул ителгән ярым татар, ярым урыс балаларын алар ярым инглиз, ярым урыс иттереп чыгаралар. Татар төректән мондый ярдәм көттеме? Татар-төрек лицейлары дип тантаналы рәвештә ачылган уку йортлары чынлыкта америкалар колледжлары булыр дип кем уйлады?

Татарстан җөмһүриятендә инглиз теле, минемчә, җитәрлек күләмдә укытыла. Һәр мәктәптә диярлек бер Аурупа теле сабаклары бирелә. Күп очракта ул нәкъ инглиз теле. Шөкер, төрекләргә кадәр дә бездә инглиз телендә белем бирүче махсус мәктәпләр күп иде. Заманчылар чүп өстенә чүмәлә өя. Ә менә төрек телендә укыткан, чын төрек мохиты хөкем сөргән мәктәп Казанда бердәнбер. Ул — мәшһүр төрек галиме Туран Язган фонды ярдәме белән Казан педагогия университеты каршында эшләп килүче төрек-татар лицее. Сүз уңаеннан, бу уку йортында гарәп теле дә тиешле дәрәҗәдә бирелә. Рухи мирасыбызның зур өлеше гарәп теленә бәйләнгән. Бу телне камил үзләштергән белгечләргә без бик мохтаҗ. Төрек фонды татарларга гына түгел, бөтен төрки халыкларга бүген зур ярдәм күрсәтә.

Заманчылар колледжы укытучысы Адәм Йолмаз миңа җибәргән хатында: “3500 километр ераклыктан килеп без сезнең балаларны татарча укытыйкмы?” — дип язган. Татарлар укытыр. Чакырыгыз, мөмкинлек кенә бирегез. Белгечләр табарга без дә ярдәм итәрбез. Туран Язган лицеенда педагогик коллектив катнаш бит.

Фәйтуллаһ Гүлән шәкертләренә әзрәк милли горурлыкларын күрсәтү дә һич комачауламас иде. Шул кадәр инглиз теленә табынырга мөмкин дип уйламаган идем. Колледжларында төрек теленә кадер сизелми. Ата-аналар комитеты вәкилләренә моны белдергәч, алар:

— Безнең балалар Төркиягә китәчәкләр һәм илнең телен базарда булса да өйрәнәчәкләр, — диде.

Менә сиңа мә! Мондый мантыйк белән без, татарлар, газиз телебезне кухня теле дәрәҗәсенә төшердек инде... Бөек төрек теленең дә базар белән чикләнүен телисезме? Бу фаҗига булмасын иде!

Ш.Госманов урамында урнашкан лицей җитәкчеләре бу

елны Төркиядә укырга 14 баланы җибәрергә ниятли. Алар үз хөкүмәтләренә мөрәҗәгать иткән инде. Һәм ни кызык, урын сорап язган хатларында укыту теле дип инглиз телен күрсәткәннәр. Менә сиңа тагын бер мә! Төркия дәүләте татар балаларын инглизча укытырга тиеш икән. Шөкер, Әнкарада, хөкүмәттә эшләүче дусларым миңа моның беркайчан да булмаячагын аңлаттылар, тынычыландырдылар. Уйлашыйк әле, мәсәлән, Финляндиягә студентларыбызны французча укытыгыз дип кем мөрәҗәгать итә икән? Төркиядә инглизча белем биргән берничә университет бар, юк түгел, әмма алар илнең үз ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Татарстан дәүләте исә инглиз теле белгечләрен үзе әзерли. Атап киткән урта мәктәпләрдән гайре, безнең укытучылар университетында чит телләр факультеты күптән эшли. Татарлар кыргый халык түгел бит. Безгә инглиз теленең әһәмиятен диңгезләр, сахралар-далалар аша килеп аңлатырга кирәкми.

Теоретик төсмерле бәхәсне шәхесара дошманлыкка китереп калдырырга маташу беркемгә дә килешми. Мин заманчыларга һич каршы түгел. Инде әйткәнемчә, Төркиядә алар искиткеч мөһим, күркәм эш башкаралар. Аларга киләчәктә дә уңышлар телим. Казандагы вәкилләрен дә хөрмәт итәм. Тирән кризиска чумган чит илдә, авыр шартларда алар батырларча эшлиләр. Ләкин атаклы фәлсәфәче Аристотельнең остазына әйткән мәгълүм сүзләрен үзгәртеп: “Заманчылар миңа кадерле, әмма хакыйкать кадерлерәк”, — дияргә мәҗбүрмен.

Эртугрул Гази ширкәте вәкилләре татарларның үзенчәлегенә игътибар итсәләр, бередәге фагыйлиятләренә дә мәдхия укылыр иде. Балаларның күпчелеге ана телен белмәвен истә тотып, лицей программаларына үзгәрешләр кертү мөмкиндер, шәт.

Исламга каршы дип гаепләүгә дә мин сәбәп бирмәдем. Милли рухны сеңдергән, милли тәрбия алган татар кешесе һәрвакыт нурлы, иманлы булыр дим. Манкорт, ягъни мәнен, миен корт ашаган бәндә мөселман булмас. Кешене тормышка мәктәп әзерли. Ул укучы зиһененең һәръягын билгели. Мәгърифәт — шәхес тәрбияләвенең нигезе һәм төп өлгесе. Чиркәү фундаменты һәм каркасында мәчет төзелмәгән

кебек, милли мәгърифәтнең шифалы нурларында коенмаган манкорт та ислам тарафдарына әйләнми. Дин — милли аңның бер чагылышы гына шул.

КамАЗ күп төбәкләрдән килгән детальләрне җыеп, йөк машиналары чыгара. Рәсәй мәгариф системасы да йөзләгән милләт баласын туплап, булачак урыс галимнәрен, урыс язучыларын, урыс мәдәнияте әһелләрен әзерли. Баланың бәдәнендә татармы, маримы каны агуы аңа мөһим түгел. Мәктәп тегермәне аша узып алар барысы да урыс “онына” әйләнәләр. Мәрхүм тарихчыбыз А.Х.Халиковның “Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе” исемле китабына гына күз төшерик. Татар урыс халкы составына этник һәм мәдәни яктан бик шәп кушылган. Аксаковлар, Балакиревлар, Булгаковлар, Буниннар, Годуновлар, Гобәйдуллиннар, Державиннар... Бу исемлекнең очы-кырые күренми. “Өлкән братка” кемнәрне генә “бүләк итмәгән” юмарт татар! Ә тегермән эшен дәвам итә...

Мәдинә апа Маликованың әсәрләрен яратып укыйм. Кызыл Ай җәмгыяте президенты буларак эшчәнлеге дә мактауга гына лаек. Шулай да аның туган телне өйрәтүгә булган карашы белән килешә алмыйм. Имеш, бу ата-ана вазыйфасы. Чу, күптән таныш сүзләр түгелме соң бу? КПСС милли сәясәтенең төп нигезләреннән бере: “Балага милли телне өйрәтү — ата-ананың үз бурычы”, — диюдән гыйбарәт иде. Совет мәктәбендә милли телләр атнага нибары 2-3 сәгать укытылды. Моны “бик хупларга кирәк” ме? Милли телне өйрәтү, ул телдә белем бирү — мәктәп, киңрәк алганда, дәүләт бурычы икәнен әле дә аңламадыкмы? Шәһәр фатирының тар кухнясында бәгъзе ата-ана баласына көнкүреш телен бирә аладыр, бәлки. Әмма Казанда туып-үскән татар язучылары, татар шагыйрьләре бармак белән генә санарлык. Чөнки Казан шәһәрендә татар мохиты хөкем иткән мәктәпләр ябылып беткән иде. Мәктәпләрдә һәм университетларда, завод-фабрикаларда һәм парламентларда яңгырарга тиеш ана теле!

Әйе, татар теле үлем түшәгенә җитте. Әмма аның хәлен тамырдан яхшыртырга, аны аякка бастырырга хөрмәтле Президентыбыз белән инде вәкаләтләре беткән элеккеге

Югары Совет барысын да эшләделәр диярлек. Мөстәкыйльлек турында Декларация, ике теллелек турында канун кабул ителде. Татар теле дәүләт теле дәрәҗәсен алды. Хәзер бу статусны тормышка ашырырга кирәк. В.Г.Гайфуллин җитәкчелек иткән министрлык шуңа хезмәт итә иде. Беләм, Васил Габдулловичка бик авыр булды. Урыннардагы мәгариф чиновниклары консерватив. Укытучыларның да күпчелеге хәлне үзгәртергә атлыгып тормый. Тел турындагы карарга каршы булган ата-аналар юкмы? Сер түгел, кайбер милләттәшләребез йөзгә бәреп:

— Татар теле кирәкми, аның белән баламның башын катырмагыз, — ди.

Шушы авыр шартларда министрлыкка матур сүзләр түгел, ә реаль ярдәм кирәк. Ул ярдәмне тик татар зыяллары гына күрсәтә ала. Без исә һаман халыкка туган телнең әһәмиятен, аның җәмгыятьтәге тиешле ролен аңлата алмадык. “Кызганыч ки, бүген кайбер “милләтпәрварлар” балаларын һәм оныкларын русча укытудан инглизчә һәм төрекчә укытуга күчерәләр. Ә туган тел һаман читтә кала. Болай эш итү зур ялгышлык, җәмәгать!” — дип яза Казаннан Х.Хәйри. Хак сүзләр. Горбачевка кадәр безнең Альбертлар, Рафинандлар, Эммалар, Клараалар һ.б. әниләре татар теленә төкереп, урыс мәктәпләренә ашыктылар. Үзгәртеп кору аларның потларын да үзгәртте. “Инглиз теле” дигән сынга табына бүген татар.

Әдипләребез миңа рәнҗемәсен, әмма монда аларның да гаебе бар. Халык белән очрашырга дип алар һаман шул биш әби белән ике бабай яшәгән татар авылына китә. Татар бүген сезнең күршегездә, күпкатлы йортыгызның бөтен уңайлыклары булган фатирларында яши. Х.Хәйри әйтмешли, ача төшик күзләребезне. Һәм шәһәр татарының туган теленә еш кына тискәре мөнәсәбәтен үзгәртү әмәлен табыйк, аның йөрәгенә үтеп керерлек сүзләр, дәлилләр эзлик.

Әдипләребезне күреп, мин балаларча сокланам. Алар бит илаһи сәләткә ия. Г.Бәширов, Ә.Еники, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев — әдәбиятның классиклары. Аларның әсәрләре — төпсез хәзинә. Ни кызганыч, бу хәзинә Казан китап кибетләрендә тузанланып ята. Шәһәр яшьләре аларны белми.

Ә танылган галимнәр М.Госманов һәм Т.Галиуллин бер үк вакытта менә дигән әдәби әсәрләр дә иҗат итүе Казан манкортларына мәгълүмме? Нурихан Фәттах, Илдар Юзеев, Мәдинә Маликова һ.б. исемнәре аларга танышмы? Шәһәр мәктәпләрендә үз әдипләребезнең иҗаты өйрәнелмәде шул. Урыс телендә язылган китапларны кимендә 3-4 меңгә җибәрүче кибетчеләр бөек Г.Исхакыйның зур җыентыгын 8 (!) сумга тәкъдим итә... Бай тарихлы татар әдәбияты бүген армиясез генерал кебек укучысыз калды. Шуны уйлыйм да, Мәдинә апа әйтмешли, утырып елыйсылар килә.

Күңел әрни. Милли мәдәният учагы сүнә. Татарның күпчелеген берни дә борчымый. Һәркемнең үз проблемалары, үз хәсрәтләре: ничек итеп оныкларга җитәрлек баеп калырга, ничек итеп балаларны чит илләрдә укытып, җылы урынга урнаштырырга. Их, татар комсызлыгыннан айнып, үзара ызгышны ташласын иде, акылына килеп, туган телен кайгыртсын иде. Алайса, күкрәгенә: “Без Казан татарлары!” — дип күпме генә какса да, Казанда аның теле дә, мәдәнияте дә юк. Алар бишмәт белән бергә авылда калдылар. Бүген җан биреп яталар. Ашыгыч ярдәм машинасы табып, тел вә мәдәниятебезне Казан хастаханәсенә китерергә кирәк. Зыялылар тырышлыгы белән алар Казанда аякка басып, төпләнеп калсалар, милләт яши, юкса — бетә...

*1995*

## ХАК ВӘ НАХАК

Кояшлы матур көн иде. Сабантуйлар чоры. Без балалар белән зур йорт җиһазлары кибетеннән чыгып барабыз. Машинабыз янына икенче бер машина килеп туктады. Аннан гарәпчә киенгән озын сакаллы яшь ир-ат, йөзе генә күренеп калган хатыны һәм кызлары чыкты. Гарәпләр дип уйладык үзләрен, чөнки киемнәре нәкъ менә Гарәбстаннан килгән кунакларныкы, чүл эсселегә өчен җиңелчә тукымадан тегелгән, җилдә җилферди. Анасы:

— Кызым, сейчас вместе пойдем, не торопись, — дигәч, боларның татар булуларын аңладык. Алар үзара урысча

сөйләшә-сөйләшә кибеткә кереп киттеләр, йөрәк исә әрнеп калды. И, татар, урыс та буласың син, гарәпләшәсең дә син, татарлыгың гына юк... Аяз Гыйләҗевнең бер мәкаләсендә укыган матур сүзләре исемә төште: “Бәйрәмнәрдә кызлар энҗеле калфаклар, бәбәй итәкле күлмәкләр кисеннәр. Чәмчәле читекләрдән кәз-кәз басып йөрсеннәр. Егетләр башында чигүле кара түбәтәйләр, аякта гармун кунычлы сафьян итекләр, иңдә җилбәгәй җибәргән йомшак камзуллар...”

Кызганыч, татар милли киемен кимәде, ана телен үз итмәде шул. Шушы нәтиҗәгә киләчәгебез билгеле иде бит. Ислам үзе белән бергә гарәп культурасын китерә, аның телен, язуын, киемен, хәтта көнкүреш гадәтләрен дә. Күптән түгел бер танышым аңлатты әле: шагыйрәләребезнең берсе (ул җырчы да бугай) моңа мөрәҗәгать итеп, иллеләп пар мунча себеркесе бар, шуларны алып кит әле дигән. Таныш гаҗәпләнеп:

— Үзең мунчага йөрмисеңме, чабыну йөрәккә ярамыймы әллә? — дип сораган.

— Гарәпләрдә, саф мөселманнарда, мунча юк, миндек юк, мин дә йөрмим хәзер, — дигән җавап алган.

Таныш кешем ул ханымны күптән белә икән, аның турында тагын кызык нәрсәләр аңлатты. Бу хатын дингә, исламга бирелеп, җырлавын ташлаган. Хихылдап йөрергә ислам рөхсәт итми, имеш. Кызының ямьле, саф татар исемен гарәп сүзенә алыштырып, яңа таныклык алган. Чират иренә дә җиткән — аны да җыр сәнгатен ташларга мәҗбүр итә ди. Мөгаен, урыс: “Заставь дурака Богу молиться — лоб прошибет”, — дип безнең турында әйтәдер...

Ошыймы-ошамыймы, хакыйкатьне танырга кирәк: исламны кабул иткән халыкларның милли сыйфатын, аларның үзенчәлекләрен мыштым гына, әмма өзлексез рәвештә, гарәп культурасы кысрыклый. Бүген Төркиядә гарәп биюләрен генә күрәбез, гарәп музыкасын гына ишетәбез. Татар, тыва яисә хакас музыкаль сәнгате белән танышкач, аларның күзләреннән яшьләр чыга, чөнки бездә сакланган әле, тегеләрдә ул юк инде. Гарәпчә киенеп, мәчет юлын гына таптасак, бездә дә калмаячак...

Тел мәсьәләсенә килсәк, бөтен төркиләр бертигез хәлдә — төшенчәләр аппараты юк диярлек. Дәүләт, сәясәт, халык һ.б. — болар барысы да гарәп теленнән кергән сүзләр. Алар намаз белән, вәгазь белән бергә керә, һичкемнән сорап тормый. Әле бит үрнәк итеп алынган идеалга омтылыш дигән нәрсә дә бар һәм ул бездә, татарларда, аеруча көчле. Без алынган эшне җиренә җиткереп үтәргә тырышабыз, әгәр берәр нәрсәгә омтылсак, ахрына кадәр барып җитәбез. Мөселман булсак, нәкъ менә Мәккә-Мәдинә кешесе кебек булыйк дибез. Боларны алдан күреп, мин үземә бик таныш булган татар-төрек лицейлары турында язып чыккан идем дә инде. Әмма мине сүктеләр, әллә ниләрдә гаепләделәр. Тиргәүчеләр арасында танылган әдипләребез Рабит Батулла белән Мәдинә Маликова да булды. Юк, мин үпкәләмәдем, аларга карата ихтирамым да кимемәде. Муаммәр Морат, Мостафа Палабыек һәм башка төрек егетләрен дә мин яхшы яктан гына искә алам. Хәсән Октан, Эртугрул Гази исемендәге лицейның элеккеге директоры, Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамладым дип йөргән, чынлыкта исә ул анда укымаган, дипломны да сатып алган икән. Аны Чабаксарда фаш иткәннәр. Бу хәбәрне укып борчылдым. Яхшымы-начармы алар безнең кардәшләр бит...

Җәллим мин Фәйтуллаһ Гүлән артыннан ияреп киткән төрекләрне, чөнки алар үз халкына хезмәт итү бәхетеннән мәхрүм. Бул син мөселман өммәтендә, бул син христиан динендә, әмма беренче чиратта үз телеңне, үз мәдәниятеңне ярат һәм олыла. Балаларга үз тарихыңны өйрәт, бөек шәхесләреңнең бөек эшләрен аңлат.

“Кыйбла кайсы якта?” — дип сорама,
Кыйбла — изге эшләр ягында!

— ди шагыйрь Галимҗан Гыйльманов.

Ул вакытта төрек егетләре Ататөрекне өйрәтми, намаз турында гына тукый дигәч, миңа ышанмадылар. Менә “Известия” газетасыннан бер өзек китерәм, үзгәрткән димәсеннәр өчен хәтта тәрҗемә дә итмим: “Председатель Центрального духовного управления мусульман по Ростовской области Джафар Бикмаев выступил против

создания в Ростове-на-Дону Российско-турецкого образовательного центра под эгидой фонда “Толеранс”. Создатели центра провозгласили своей целью знакомство с культурой и историей Турции и изучение турецкого языка. У муфтия другие сведения.

Как считает Джафар Бикмаев, к открытию центра имеет отношение турецкая религиозная организация “Нурджулар”, и поэтому под вывеской образовательного учреждения может скрываться религиозная секта, близкая по духу ваххабитам.

— Глава “Нурджулара” Фатуллах Гюлен связан с ваххабитами Саудовской Аравии и находится в изгнании в Америке за попытку совершения государственного переворота в Турции, — сообщил “Известиям” Джафар Бикмаев. — А это уже повод для размышлений. Лицеи Гюлена, которые были больше похожи на казармы, турецкие власти закрыли. А у нас им — “зеленый свет” (№ 74 (25912), 25 апреля 2001 г.).

Мөфти сүзләренә ни өстим икән? “Төрек татарга ярдәм итәрме?” дигән мәкаләм чыккан “Шәһри Казан” газетасы санында шагыйрь Рафаэль Ярулла парчалары да бирелгән. Бәлки, шуларның берсе урынлы булыр:

Җитте сиңа, уян, татар,
Үшәнлегеңне ташла,
Баш күтәреп, горурланып
Татарча сөйли башла!

*2003*

# МОЯ АМЕРИКА НЕ БОЯЛАСЬ!

Базарда мәхшәр иде: чырылдап хатын-кызлар чабышты, берничәсе хәтта таеп егылды, сатучылар, басып чыгарган үрдәк бәбкәләре суга кереп киткәч, яр буенда арлы-бирле йөргән тавык сыман мескен хәлдә калды, чөнки малын ташлап качалмады, ир-атлар исә китәргәме-юкмы дигәндәй шау-шуны читтән күзәтте. Ыгы-зыгының уртасында үзеннән зуррак күсәк тоткан вьетнам кешесе булды. Ерактан килгән сәүдәгәрнең арыслан сыман ярсып күсәге белән бер кизәнүе булды, өстенә йодрык төеп килгән ике җирле

егетнең табаннары гына ялтырады. Әмма җыелган халык аларның абына-сөртенә куркып качуыннан түгел, ә батыр вьетнамлының: “Моя Америка не боялась!” дигән тапкыр сүзләреннән көлеште. Вьетнамлының урысчасы чамалы гына булса да, һәркем аның: “Без американнардан да курыкмадык!” дияргә теләвен аңлады. Һәйкәл сыман агач ящик өстенә менеп баскан килмешәк пәһлеван кадәр булып күренде бу мизгелдә. Аңа сокланып хәтта “Молодец! Молодец!” дип кычкырдылар.

Герой үзенең пьедесталыннан төшеп, халык таралыша башлагач кына мин ул вьетнам кешесен таныдым — унлап минут элек кенә Тукай урамындагы трамвай юлы ягыннан кием-салым базарына кереп барганда күрдем ич мин аны, нидер сатып тора иде. Әмма ул бик ябык, тәбәнәк иде бугай. Табаннарын ялтыратучыларга да игътибар иткән идем әле, сөйрәлчек бер кызны ияртеп, алар кемгә килеп бәйләнергә белмичә йөрде. Димәк ки, вьетнамлыны җиңел табыш дип уйлады болар. И, мескеннәр, әлегә иде үзләренә батыр халык вәкиленнән, ярый әле качып котылдылар. Тарихны белергә кирәк шул — Вьетнам заманында Америка кадәр Американың арт сабагын укытты ул. Карагыз әле, нинди кызык бу дөнья: халыкның олы җиңүе аның барлык улларына-кызларына да гаҗәеп көч һәм гайрәт бирә икән бит...

*2000*

# ӨЙЛӘНҮ

*(татар малайларына ачык хат)*

Әй, улым, өйләнергә җыенгансың. Бу тормышыңның иң мөһим адымнарыннан берсе булачак. Безнең халык бу адымның гаять зур әһәмиятен белдереп: “Ир-атны кеше иткән дә хатын, хур иткән дә хатын”, — ди. Әгәр бу эшеңдә уңсаң, киләчәк көннәрең якты вә матур, шатлык тулы булыр. Юкса инде, һәр көнең сагышка күмелер. Мин гаиләләр тормышын күзәтеп, еш кына ирләрнең юньсез хатыннары аркасында эчкечелеккә бирелүен күрәм. Акыллы хатын-кыз кулында ул эшчән ир алтын куллы оста, мөхтәрәм зат булыр

иде. Явыз хатын-кызга очрап, күпме ир, төзәлмичә, үз-үзенә кул сала. Әйе, явыз хатын дөньядан биздерә...

Гаиләдә күп нәрсә хатын-кыз кулында. Без, ирләр, еш кына берни үзгәртә алмыйбыз. Хатының акыллы булса, синең дусларың да күп булачак, чөнки зирәк хатын аларны тәмле ризык әзерләп, ачык чырай белән каршылаячак. Чын дусларың белән тормышың җиңел барачак. Ише күпнең көче күп.

Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк дөнья көтәргә.
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар усак,
И-и, аерылмабыз дус булсак,

— дип җырланса да, юньсез хатын дусларыңны тиз биздерәчәк, сине хәтта туганнарыңнан да аерачак.

Иң көчле ир дә хатын-кыз янында көчсез. Улым, өтәчләнеп, йортымда барысы да мин теләгәнчә булачак дип уйлама. Әгәр ялгышсаң, син ул хатаңны йодрык белән генә төзәтә алмаячаксың. Хатын-кызны кыйнап та, үгетләп тә үзгәртеп булмый. Ул нинди холык белән җитешкән, гомер буе шуны куачак. Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас. Гаиләңдә көч куллану һич кирәк булмасын. Каргыш-елаш кергән йортның бәрәкәте кача, тормышның яме калмый. Без бу дөньяда кунак кына. Һәр көннең кадерен белеп, һәр көнгә сөенеп яшәргә омтыл. Хатының синең якын дустың, фикердәшең, тормыш терәгең булсын. Шул вакытта гына син бәхетле булачаксың.

Өйләнү мәсьәләсендә ашыгып эш итмә. Иң элек, син сайлаган кыз күңелеңә ятышлы булсын. Аны уйлау белән үк тирә-як дөньяң яктырып китсен.

Күбәләккәй гөлгә кунган,
Гөлдә булгач оясы;
Минем күңелем сиңа тарта,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Син бит күңелем кояшы.

Кояшка тиңли халык сөйгән ярны. Син ул кеше белән гомер итәчәксең. Әгәр ул сиңа ошамаса, дөнья да ямьсез күренәчәк. Кызның байлыгына да, дәрәҗәсенә дә кызыкма. Алар мөһим түгел. Уңган хатын белән байлыгына да, дәрәҗәсенә дә син үзең ирешәчәксең.

Димәк ки, сиңа насыйп булган кешене күңелең үзе табачак. Һич шикләнмичә бу эшне күңелеңә тапшыр. Әмма сак бул. Күңел авазы нечкә, аның зәгыйфь тавышын ишетергә авыр, башка авазлар белән бутап, ялгышырга мөмкин. Хәзер дөнья ярым-шәрә кызлар белән тулы. Алардан ерак йөр. Кулларында сыра шешәсе, авызларында тәмәке. Акыллары сай, мөстәкыйль фикер йөртә белмиләр. Алар маймыл сыман — телевизордан яисә башкалардан ни күрсәләр, шуны кылананалар. Акчага кызыгып ирләр белән булалар, гаиләләрне таркатып, балаларны ятим итәләр. Бозык хатыннардан саклан. Алар чирле булыр, бала тапмас, тапса да баласы юньсез булыр, чөнки анасына охшар. Син андый хатын-кызларны урап уз. Әйе, аларның ачык ботларын күреп, эчеңдә әллә ниләр була сыман. Әмма бу күңел авазы түгел, бү җенси омтылыш кына. Түбәннән килгән сигналларны югарыдан җибәрелгән ишарәтләр белән бутама.

Әйткәнемчә, кыз табу эшен күңелеңә тапшыр. Күңел бит ул күк көчләре белән бәйле. Бу кыз миңа ошый дип аның артыннан чабарга яисә башка егетләр белән кыз өчен сугышып йөрергә һич ярамый. Кеше бәхет өчен яратылган, бәхет ул үзе килә, аңа киртәләр генә куймаска кирәк. Синең мәхәббәтең кояш нурларын сипкән якты көнне үзе каршыңа килеп басачак, сиңа йомшак кулларын сузачак...

Үз күңелеңне төрле шартларда тыңлап кара. Кызның ата-анасы, туганнары белән таныш, нинди мохитта яшәвен күр. Әгәр кызның ата-анасы чиста, пөхтә йортта бер-берен яратып, хөрмәт итеп яши исә, бу һичшиксез синең күңелеңә җылы тәэсир итәр. Аеруча, синең булачак кайнанаңның кайнатаңа мөнәсәбәте әһәмиятле — бабаңны олылап, кадерләп торалар икән, хатының да сине олылаячак, яратып тәрбияләчәк. Бабаң эт тормышында булса инде, син дә аннан ерак китмәячәксең, синең тормышың да аяныч булачак. “Кош оясында күргәнне оча”, — ди халык. Кыз бала үсеп

килгәндә үк, ата-анасының тормышын күреп, булачак гаиләсенең моделен төзи.

Сөям дип йөргән кызыңны төрле хәлләрдә күзәт. Әгәр ул синең янда әүлия сыман булып, өеңдә аяк астындагы песине тибеп җибәрә икән, димәк ки, кызның әүлиялеге ялган. Песи тәгәрәп киткән мизгелдә күңелең сиңа ишетелер-ишетелмәс кенә: “Бу кыз белән ялгышасың”, — диячәк. Шәфкатьле, миһербанлы кеше һәркем белән шундый. Сиңа елмаеп, башкаларга кычкырган кыздан шәфкать көтмә.

Күңел авазын тою җиңел түгел. Өйләнеп ялгышырга мөмкин. Дүрт аяклы ат та сөртенә. Яратышып йөргәндә кызлар бик яхшы. Туйдан соң инде кайберен танып булмый, андые ирне үзе теләгәнчә биетә башлый. Һәркемдә дә явызлыкка, мәрхәмәтсезлеккә каршы торырлык көч булмый. Бигрәк тә нечкә күңелле кешеләр гаҗиз. Улым, каты бәгырьле хатын сине сындырып, идән чүпрәге сыман кулланачак. Соңга калма, барлык ихтыяр көчеңне җыеп, андый хатыннан аерыл. Бернигә дә карама. Баш сау булса, бүрек табылыр. Нык һәм көчле булсаң да, мин җиңәм, өстен чыгам дип хатының белән көрәшеп йөрмә. Бу җүләрлек. Гаилә — көрәш мәйданы түгел, киресенчә, хозурлык, ләззәт бирүче чәчәк аланы ул.

Аерылышып йөргән авыр көннәрдә ата-анага, туганнарыңа таян, алар янында бул.

Биек тауга менгән чакта,
Уртасында җил-давыл,
Кил, уртаклаш хәсрәтемне,
Ялгызыма бик авыр,

— диярлек чаклар була ул тормышта. Бикләнеп, кайгыга чумма, дөньяга чык. Булып узган хәлләргә карата көлемсерәп куй — тормыш уен гына ул, бернине дә артык җитдигә алма. Уңмаган хатыныңны да сүкмә. Дөресен әйткәндә, ул да синең белән бәхетсез булыр иде. Чөнки ул сиңа исәп-хисап итеп кенә чыккандыр, яратып түгел. Яраткан кешене һич кенә дә җәберләп булмый.

Ник кеше мондый бәхетсезлеккә очрый? Сәбәпләр төрле

булырга мөмкин. Бәлки, син үзең берәр кызны рәнҗеткәнсеңдер һәм аның каргышы төшкәндер... Кешеләр белән бик дикъкатьле бул, явызлык кылудан саклан. Һәркемгә яхшылык кына телә, үзең яхшы булсаң — кеше дә сиңа яхшы булыр. Иш ишен табар, тычкан тишеген табар, ди. Киләчәк гаилә тормышын яшь кеше башта үз аңында формалаштыра. Булачак хатынын да, балаларын да ул үз уй-хыялларында күрә. Бу уйлар белән бик сак бул. Булачак хатыныңны фәкать шәфкатьле, миһербанлы кеше буларак күр. Ызгыш-талашны күз алдына һич китермә, чөнки киләчәгебез күктә языла, безнең уйларыбызга таянып языла. Ни уйласак, ни сорасак, күк көчләре шуны бирә. Күңелеңә якты, матур уйлар гына салып куй. Изге уй йөрткән адәмгә яшәве җиңел, балачактан ук уйның бары тик яхшысын гына уйларга гадәтлән.

Бу уйларыңда булачак хатының, әлбәттә, үз милләтебез кызы булсын. Татар кызлары яхшы булып, башкалар начар булган өчен түгел. Татар тәти дә, урыс яман дип әйтү ялгыш. Һәр халыктагыча, татарның да яхшысы да бар, яманы да күп. Казанда урыслар белән аралашып яшибез, алар арасында мөлаем, итагатьле хатын-кызны еш күрәбез. Шул ук вакытта авылдан килгән надан, бозык татар кызлары белән дә тулай тораклар тулы...

Катнаш никахларга “яхшы-начар кеше” яссылыгында гына карарга безне социализм елларында өйрәттеләр. Имештер, килениеӊ (кияүнең) кайсы милләттән булуы түгел, нинди кеше — яхшымы яисә начармы — булуы әһәмиятле. Бу демагогиянең классик үрнәге. Әллә күпмиллионлы татар халкы арасында әйбәт кыз беткәнме?

Катнаш никах проблемасында мәсьәлә бөтенләй башка нәрсәдә ич. Әйтик, яһүдиләрдә баланың милләте анасына карап билгеләнә. Ягъни, синең кәләшең яһүди кызы икән, балаларың да яһүди булачак. Теләсәң, син үзең дә гаиләң белән Израильгә күчеп китеп, яһүди халкына кушыла аласың. Яһүдиләр дөньяда иң акыллы халыктыр — алар һәр мәсьәләгә, һәр эшкә иң дөрес юл белән киләләр. Без, ирләр, өйдә аз булабыз ич, бала ана кулында, ана тәрбиясендә. Юкка гына: ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс,

дип әйтмиләрдер. Бу мәкаль тәрбия эшендә ананың хәлиткеч ролен күрсәтмиме? Тагын бер сорау: бала нинди телдә сөйләшәчәк? Әлбәттә, ана телендә. Ата нинди генә шәп кеше булмасын, бала ана сүзен сөйләячәк, хатын тукыганны кабатлаячак...

Әйбәт урыс кызына өйләнерсең, тату яшәрсез, әмма балаларың урыс булып үсәчәк. Алар хәтта синең исемеңне дә бозып әйтәчәк. Үлгәч, сине мөселман зиратына күмәчәкләр. Христиан динендәге балаларыңның каберенә килеп йөрүе бик икеле. Шулай итеп, синең бу дөньяда дәвамың, нәселең дә калмый, сине искә алучы да булмаячак...

“Без Наташа белән бер-беребезне үлеп яратабыз, бу безнең икебезнең генә эше, арабызга тыгылмагыз!” — дип ярсый татар егете. И-и, мескен! Олы хатаңны син туй көнендә үк аңлый башлаячаксың. Син сөйгән Наташа кеше яшәми торган утраудан килмәгән ич, ул дәү бер милләт кызы, бөтенләй башка дөнья, башка культура вәкиле. Аның ата-анасы, күпсанлы туганнары, дуслары бар. Туй мәҗлесендә алар бер якта, синекеләр исә икенче якта утырачак. Һәр кошның үз тавышы үзенә хуш дигәндәй, алар үз җыр-биюләрен якын итәчәк, синекеләр исә баш бирмәскә, таныш моңнарга омтылачак. Нигә кирәк бу көрәш? Наташа Иваны белән, ә син үз татарың белән бәхетле булсагыз яхшырак түгелме? Уйлан, улым, уйлан. Уйларың да төпле булсын. Өйләнгәч, Хуҗа Насретдин мәзәгендәге сыман, йорт-җирең, тормышыңның асты өскә килмәсен. Хуҗа өй салдырган вакытта балта остасына:

— Син идәнгә дигән такталарны түшәмгә, ә түшәмгә дигәннәрен идәнгә җәй, дигән имеш.

Балта остасы, гаҗәпләнеп, ни өчен алай эшләргә кирәк, дип сорагач, Хуҗа:

— Тиздән мин өйләнәчәкмен. Ә кеше өйләнгәч өйнең асты өскә килә, диләр бит. Менә мин шуңа алдан ук чара күрәм инде, дип җавап биргән.

* * *

Уңышлы өйләнеп, матур гаилә коргач та, уяу бул, улым. Хатыныңа һәрвакыт аны күреп гашыйк булган беренче мизгелдәге сыман ихтирамлы бул. Ул синең хатының, әмма малың түгел. Һәр иртә сез яңадан туасыз, бер-берегезне беренче тапкыр күрәсез. Бу яңа туган көнне дә әле генә танышкан кебек гөрләшеп яшәгез.

*2003*

# АЙНЫҢ КОЯШ БЕЛӘН КӨРӘШЕ

Төркиләр Яңа елны көн белән төн тигезләшкән вакытта — нәкъ 21 нче мартта каршылый. Бу көнне кояш зодиакның хәмәл (кузы) йолдызлыгына килеп керә. Шуңа айның үзен “Хәмәл ае” дигәннәр. Ә татарлар аны “Нәүрүз” дип йөрткәннәр. Нәүрүз бәйрәме үз исемен фарсы теленнән алган — яңа көн, яңа ел дигәнне аңлата ул.

Балачакта мин гаҗәпләнә идем: ничек инде ул кыш уртасында яңа ел, ягъни яңа көн, яңа тормыш башлансын, ди. Кеше тормышы табигать халәтенә, аның фасылларына бәйле ич, бу элек тә шулай булган, хәзер дә дөнья әлләни үзгәрмәде. Яңарыш ул яз белән бергә килә, табигать анабыз йокысыннан уянып, безгә яңа тормыш китерә.

Кышны озатуга, язны каршылауга багышланган да инде Нәүрүз. Аврасия (Евразия) киңлекләрендә яшәүче төрки халыклар бу көнне соңгы берничә мең ел дәвамында күтәренке күңел, котлау-тәбрикләр белән каршылый, изге тауларда учаклар яга. Миллионлаган учак яктысы дөньяны кышкы шакшылыктан тазарта, аны сафландыра, безнең күңелләргә үтеп кереп, шатлык сала.

Алдан ук йола ашлары әзерләнә, өстәлгә җиде төрле ризык куела. Табыннар яшел уҗым белән бизәнә, ул яңарыш билгесе булып тора. Орлыкларның ничек тишелүенә күрә, киләсе ел уңышы юрана.

Кавказ төркиләрендә Яңа ел башланган көнне яшьләр, бала-чага өйдән-өйгә йөреп, йорт хуҗасына, аның гаиләсенә исәнлек-саулык, бәхет-куанычлар теләп, “нәүрүз әйтә”. Яңа

ел табынына йомырка, калач, сыр кебек ризыклар әзерләп куела, төрле-төрле камыр ашлары да пешерелә.

Себер төркиләре нәүрүз көннәрен "әмәл", "әмил" дип атыйлар. Әмил бәйрәме көнне җигүле атларга утырып, урам әйләнәләр, йортларга кереп, тукач (тук аш), вак күмәчләр, кәнфит-прәннекләр өләшәләр.

Бәйрәм көннәрендә казахлар — алар йоланы "Улысның олы көне" дип атыйлар — күңел ачалар, кунак чакыралар, үз туганнарына баралар. Һәркем җиде йортта кунак булып, үзе дә җиде кунак сыйларга тиеш.

Алтайлыларда Нәүрүз бәйрәменең мөһим өлеше — борынгы бабалар рухларына корбан чалу. Һәр гаилә рухларны мул итеп сыйларга тырыша. Җирле камнар да эшкә керешә, алар гыйбадәтләрен башлый.

Элек, исламга кадәр, мондый корбан чалулар, төрле дини ритуаллар барлык төркиләргә дә хас була. Әмма ислам дине тәңречелеккә килеп тоташкан Нәүрүз бәйрәмен катгый рәвештә тыя. Муллалар "шайтан туена" җыелмагыз дип, бәйрәм иткән халыкны куып тарата. Башлап йөрүчеләргә каты җәза бирелә. Кояшка карап түгел, айга карап яшәгез дип өйрәтә миссионерлар бабаларыбызны. Барлык мөселман илләрендә ай календаре кулланыла бит. Еллар исәбе безнең эраның 622 нче елының 16 июленнән башлана. Бу көнне Мөхәммәт пәйгамбәр һәм аның якын тарафдарлары туган шәһәре Мәккәдән Мәдинәгә күчәргә мәҗбүр булалар. Алар качып котыла һәм яңа дин тарата башлый. 1 нче мөхәррәм мөселман календаре буенча Яңа ел бәйрәме. Ул кояш календаренең төрле көннәренә туры килергә мөмкин. Мәсәлән, бу елны гарәпләр Яңа елны февраль аенда каршыласа, берничә елдан ул июль аена туры киләчәк. Менә моны төркиләргә аңлату кыен була да инде. Кояшка карап көн иткән күчмәләр муллаларны игътибар белән тыңлый, ризалашып башын селки һәм ... көннәр җылыта башлау белән Нәүрүзгә әзерләнә. Халык бирешми, күңелле, игелекле бәйрәменнән баш тартмый. Ислам Нәүрүз белән килешеп, аны кабул итәргә мәҗбүр була. Дөресрәге, мөселман руханилары тешен кысып Күк Тәңре чорыннан калган бу йоланы күрмәмешкә салыша. Әлбәттә, күчмәләр дә

ташламаларга баргандыр. Төрекләр Нәүрүз бәйрәмен “Эргенекон” дип атый. Бу сүз борынгы төрки телдән үк килгән һәм ул шулай ук яңа көнне яисә олы көнне аңлатканын чамаларга мөмкин. Мөгаен, бәйрәмне саклап калу өчен бабаларыбыз аның исемен фарсы сүзе артына качырганнардыр.

Калганын үзегез дә беләсез инде. Дуамал большевиклар Нәүрүзне мөселман бәйрәме дип яңадан тыя. Әмма социализмның гомере бик кыска була, Нәүрүз исә мәңгелек...

*2004*

# АЛФАВИТ ТУРЫНДА

Гел авыр тормышта яшәгәнгәме инде, татар алфавит мәсьәләсендә үзен базарда галош сайлаучы сыман тота, ягъни кайсы җайлырак ди. Латин алфавитына күчсә, Аврупага якыная, фән казанышларын, компьютерын һәм интернетын җиңел үзләштерә ул. Гарәп әлифбасына кире кайтып, ислам динен көчәйтә, ә инде урыс язуы булган кириллицада калып, социализм чорының әдәби мирасын саклый имеш.

Ә менә дөньяның башка халыклары кыска гомерле файда артыннан куучы беркатлы татар кебек фикерләми. Нигә грузиннар һәм әрмәннәр кириллица Җир шарының алтыдан берендә чәчәк аткан елларны да үз язуларына ябышып ятты? Нигә кытайлар балаларының башларын катырып, меңләгән иероглиф өйрәтә? Нигә урыс үзе шул ук җайлы латинга күчми? “Кириллица нәкъ менә урыслар өчен яратылган, ул үзе белән бергә безнең мәдәниятебезнең һәм христиан рухыбызның аерым кодын алып килә”, — дип яза урыс галиме В.С.Орлов. Бүре мең ел үткәч тә бүре булып кала, ә дуңгыз — шул ук дуңгыз инде ул. Аларны нәселдән-нәселгә күчеп килгән код саклый. Халыклар да нәкъ шулай — башкалар арасында эреп юкка чыкмас өчен аларның ата-бабадан калган үз кодлары булу зарури, бүре яисә дуңгызның биологик геннары сыман. Һәм бу код телдән башка яшәми — милләт телдән башлана. Милли тел сүз экологиясе күзлегеннән караганда — халыкның гены ул, ди шул ук галим. Бу ген исә алфавиттан башлана.

Төркиләрнең үз алфавиты — рун язуы. Якынча 2-3 мең ел элек барлыкка килгән. 18 нче гасырга кадәр диярлек кулланышта булган, үзен ислам кысрыклап чыгарган.

Түбәтәен маңгаена төшереп, татар башын кашый. Кайвакыт, үз акылың җитмәгәндә, башкалардан өйрәнергә була. Япон телендә өч алфавит кулланыла: хирагана, катакана һәм канджи. Канджи-кытай иероглифлары ул, алар Япониягә алтынчы гасырда үтеп керә. Хирагана һәм катакана исә японнарның үз язулары.

*2004*

# ӨЧ СУМ

Сез көлмәгез — өч сум ул хәзер акча түгел. Элек исә өч сум зур акча иде. Уйлап карагыз: студентның айлык стипендиясе кырык сум, ашханәдә бер ашап чыгу илле-алтмыш тиен, димәк ки, өч сум ике көнгә диярлек җитә иде. Менә шул өч сумымны икетуган абыем кесәсенә тыгып куйды. Чыгарып биргәндә, ул миннән акча алмас дип уйладым.

— Син нәрсә инде, Фирдүс, разве синнән, студенттан, акча аламмы мин, — дип кире бирер дип көттем. Чөнки Ф. абый калхузда алдынгы механизатор, акчаны мул ала, урак өстендә дүрт йөз сум бирәләр икән. Узган гасырның сиксәненче елларында калхузчыларда акча бар иде, К. авылы халкы да акчасыз калмады.

— Булмаган акчаларыңны сарыф итеп, ул К. авылында нишләп йөрдең? — дип сорарга мөмкин. Мин кунакка кайттым. Җәйге каникуллар ич. Авыл малаена зур шәһәрдә читлек кошы сыман яшәүләре бик авыр, күңел һәрвакыт саф һавага, инеш суына, киң кырларга, хозурлык бирүче урманнарга тарта. Менә шулай, авылны, туганнарны сагынып кайттым. Кичен инде Ф. абый белән клубка киттек, концерт була икән. Гәпләшеп барабыз. Абый тел астыннан “т-тсы” сыман бер аваз чыгарып сөйли, аның һәр җөмләсе шулай башлана.

— Т-тсы, концерт түләүледер инде.., — ди бу. Менә шул чак мин егетләрчә:

— Миндә акча бар, мә ал, — дип өч сумны суздым. Өч сумым кире кайтмады. Концертка билет бәясе бер сум алтмыш тиен иде бугай, аерылмасы да кайтарып бирелмәде...

Хәзер, күп еллар узгач, бу өч сумны ник искә төшерәм? Хикмәт өч сум акчада түгел. Телевизордан бәйсез Үзбәкстанны күрсәттеләр. Кореялеләр белән берлектә зур машина заводы төзегәннәр, җитештергән продукциясен чит илләргә дә саталар икән. Шат чырайлары, өс-башларыннан мул, бәхетле тормышта яшәүләре күренә. Өч сум зур акча булган теге елларда Үзбәкстан хәерче бер республика иде. Халкы рәхимсез рәвештә мамык плантацияләрендә агуланды, җитәкчеләре исә даими туган-тумачаларын яклый дип җәберләнде. Үзбәкстанда клан (ыруг) системасы бетерелмәгән дип, күпсанлы җинаять эшләре ачылып торды. Ә узбәкләр чигенмәде, Мәскәү җибәргән килмешәкләрне үз араларына кертмәде. Ул елларда ярым ач яшәсә дә, үзбәк халкы баш бирмәде, туганлыктан ваз кичмәде, кан кардәшлек — милләтнең нигезе булуын онытмады. Тиздән бу нык халык дәүләтле дә булды. Татар исә татар башын ашады, ул мескен өч сумга кызыгып калды...

*2004*

## САК БУЛЫГЫЗ!

Соңгы елларда туклану белән бәйле әдәбият ишәйде. Безне нәрсә, күпме һәм ничек ашарга икәнен өйрәтәләр. Бу китапларда аерым киңәшләр генә түгел, тукланугa өр-яңа караш, бөтен бер фәлсәфә бирелә. Алар халыкта бик популяр: һәр җирдә диярлек ач торуның файдасы, организмны чистартырга кирәклеге турында сөйлиләр, итне сүгеп, кәбестәне мактыйлар.

Күбесенчә Һиндстаннан таратыла торган бу карашлар ашау-эчү рәвешебезне тамырдан үзгәртергә чакыра. Менә бу әзрәк шикләндерә дә инде — кискен үзгәрешләр гадәттә яхшыга китерми ул. Юк, бу китапларны дошманнар язып тарата дип уйламыйм. Бәлки, ниятләре изгедер. Әмма Вәлигә файдалысы Галигә зарарлы булу мөмкинлеген онытмыйк.

Һиндстанда яшәү шартлары бер төрле, ә бездә бөтенләй башка. Тегендә яшелчә ашап та яшәргә мөмкиндер, ә бездә итсез булмый. Индуслар өчен сыер изге зат булса, татарларга ул ит белән сөт чыганагы гына. Гасырлар буенча безнең халык үзенчә тукланган. Гомумән, һәр халыкның үз ризыгы: берсе диңгездән туклана, икенчесе кишәрлектән, ә өченчесе асраган хайваннардан. Дөнья шулай яратылган. Ул китапларда язылганнарга ияреп, чукчалар балык ашамыйча яшелчә эзләсенме?

Без, төркиләр, элек-электән ит һәм сөт ризыклары яраттык. “Дөрес туклану” китаплары аларны гел яманлый, зарарлы дип күрсәтә. Әмма Борынгы Рим, Греция һәм Мисыр табиблары ук сөтне тормыш согы һәм сәламәтлек чыганагы дип атаганнар. Сөттә 120гә якын кыйммәтле элемент җыелган. Яшьләр өчен кирәкле 20дән артык аминокислота бар. Ул кальций, фосфор тозларына, йод, бакыр, кобальтка бай. Әчегән сөт продуктларын эчү аеруча файдалы. Танылган урыс физиологы И.И.Мечников катык һәм кефирның күп авырулардан саклавын исбат иткән. Теләсә нинди әчегән сөт продуктлары черү процессларыннан саклаучы миллиардлаган бактерияләрдән тора. Галим шундый нәтиҗәгә килгән: “Без юан эчәктәге черү матдәләре белән агуланып картаябыз”. Эшкәртелеп бетмәгән азык калдыкларында череткеч микроблар мыжлап тора. Алар аркасында барлыкка килгән агулы матдәләр канга үтеп керә һәм нигездә бавыр тарафыннан нейтральләштереләләр. Әмма кайберләре шактый вакыт канда йөри икән. Мечниковның әйтүенчә, нәкъ менә шулар организмыбыз күзәнәкләре картаюга китерә икән. Катык эчү канның химик составын шактый яхшырта, чөнки юан эчәктә таркалу процессларын киметә. Кешенең кәефе күтәрелә, кайбер хроник авырулары бетә, организм энергия белән тула. Шуңа күрә теләсә нинди әчегән сөт продукты — картаюдан менә дигән чара! Шулай ук итсез дә яшәп булмый. Ит ул организмга аксым бирә. Баш авыртканда яңа пешкән итне тозлап ашарга киңәш ителә.

Чит-ятларның тәкъдимнәре белән сак булыйк. Организмны чистартырга кирәк, диләр безгә. Әмма андый процедуралар (гап-гади клизма инде ул) зарар гына китерә. Ник дисәң, юан

эчәкнең өчтән ике өлеше файдалы микроорганизмнардан гыйбарәт. Шулар булмаса, эчәкләр дөрес эшләми дигән сүз. Ә клизма һәм рекламалана торган препаратлар шул файдалы микроорганизмнарны тулысы белән юып төшерәләр. Бу исә үз чиратында дисбактериозга һәм башка авыруларга китерә. Организмның чиста булуын теләсәң, күңелең чиста, ризыгың хәләл булсын. Аз аша, күп хәрәкәтлән.

Аз аша, әмма ач та торма. “Ачлык могҗизасы” — көнебезнең иң популяр уйдырмасыдыр. Ач тору ашказанының эшчәнлеген боза, организм таләп иткән матдәләр җитмәвенә китереп, аны хәлсезләндерә, авыруларга каршы тору сәләтен киметә. Кешенең йөзе ямьсезләнә, яңаклары сәлперәеп төшә. Ачлык — тән өчен көчле стресс ул. Пошаманга төшкән күзәнәкләр кинәт саранла804налар, көчне сарыф иттермиләр, аны май буларак запаска җыя башлыйлар. Ачлыкны туктату белән югалган килолар җитез генә кире кайтачак һәм аларга запаска дип җыелган май өстәләчәк...

Безне туклanyrga өйрәтүче китаплар банан, киви ише чит илләрдән китерелгән җиләк-җимешне мактый. Экзотик җиләк-җимешләрдән өстәлләребездә иң еш күренгәне, мөгаен, банандыр. Без аның читтән китерелә икәнен дә оныттык бугай. Шулай ук киви да арзан, күпләр аны ала. Әмма безнең өчен чит-ят булган җиләк-җимешне авыз иткәндә, сак булу зарур, чөнки аллергия китереп чыгарулары бар. Һәр кешенең организмы үзенә бер төрле.

Үзең яшәгән җирдә җитешкән ризыкны ашау — иң акыллысыдыр. Өстәлдә сөт ризыклары, кош һәм хайван итләре, йомырка, икмәк, токмач һәм ярмалар булырга тиеш. Карабодай, солы, арпа, тары ярмалары, эре итеп тарттырылган оннан (көрпәле булса яхшырак) пешкән икмәк үсемлек җепселләренә бай азык-төлекләр буларак, эчәкләрнең эшләвен яхшырталар. Җиләк-җимешләрдән үз бакчаларыбызда үскән алма, слива, карлыган һ.б. аеруча файдалы. Азыкларның күптөрле булуына ирешергә кирәк. Аларның барысын да аз-азлап ашау организмны туклыклы матдәләр белән тәэмин итә.

Әллә кемнәргә ияреп, мөгез чыгарып маташмыйк, ата-бабаларыбыз кушканча тукланыйк.

*2004*

# ЯҺҮДИЛӘРНЕ НИК ЯРАТМЫЙЛАР?

Татарлар белән яһүдиләрне яратмыйлар. Татарларны ник яратмавы аңлашыла бугай. Һун бабаларыбыз заманында Аврупаны дер селкеткән. Мескен аврупалылар ярлы, пычрак шәһәрләрендә төрле чирләрдән кырылып, үзара сугышып ятканда, аз санлы гаскәр белән килгән Аттила аларның котын алган. Дин башлыклары папа тезләнеп, Аттиладан Римны тар-мар итмәвен ялварган...

Аттила атлары куптарган тузан басылып, тынычланулары гына була, Чыңгызхан яугирләре күренә. Яңадан дөньяда: “Татарлар килә!” — дигән аваз яңгырый, аларга каршы торырлык көч булмый. Әйе, безнең бабалар бик көчле булган шул, алардан һәркем курыккан, шуңа безне яратмыйлардыр да инде. Куркулары әле дә чыгып бетмидер... Ул заманда татар дәүләте — иң көчле дәүләт. Татар бөтен дөньяга баш булган, ул ни теләсә, барысын да кыла алган. Аврупа корольләре башкала Сарайда хан хозурында булыр өчен атналар буе көткән. Ханга баш салмаган патша калмаган, урыс кенәзләре дә килеп ярлык теләнгән. Тарихи карталарга карап гаҗәпләнәсең — бөтен Аврасиягә диярлек зур калын хәрефләр белән “Тартария” дип язылган... Көчлене һәрвакыт яратмыйлар. Бүген Америка Кушма Штатлары иң көчле дәүләт һәм аны шулай ук күрә алмыйлар...

Татарлар белән барысы да аңлашыла кебек, менә яһүдиләрне ник яратмыйлар? Аспирантурада укыганда мин бер яһүди белән таныштым. Бездә аларны гел яманлыйлар, шуңа мин дә башта бу егеткә шикләнебрәк карадым. Әмма ул бик әдәпле һәм ярдәмчел иде. Без дуслашып киттек. Ул миңа үз халкының нахакка рәнҗетелүен аңлатты.

Яһүдиләрнең тарихы бик гыйбрәтле. Рим империясе заманында еврейләрне үз җирләреннән куалар һәм алар дөнья буенча сибелә. Һәр җирдә алар азчылык, һәр җирдә аларга килмешәк дип карыйлар. Михнәтле тормышта исән калу өчен алар бердәм булырга, бер-берсен якларга мәҗбүр була. Яһүдиләрнең милләтпәрвәрлеге шул заманнардан ук киләдер...

Аларны кара эштә эшләмиләр, акча гына санап утыралар дип гаеплиләр. Яһүдиләрне гасырлар буе эзәрлекләгәннәр, һәр җирдән куганнар. Мондый шартларда алар, әлбәттә, җирдә эшләмәгәннәр, гадәттә сәүдә белән шөгыльләнгәннәр. Акчаны алып качарга җиңел ич. Израильдә яһүдиләр җирне дә бик теләп эшкәртә, башка төрле эштән дә курыкмый.

Алар бик акыллы халык дию дә ялгыштыр, чөнки гомумән, акыллы яисә тинтәк милләтләр юк. Әйе, яһүдиләр элек-электән укырга, белем алырга омтылган, әмма бу теләк шул ук сәбәп — хәятнең авыр шартлары белән бәйле. Үз-үзеңне яклар өчен көчле булырга кирәк, ә белеме булган меңне егар, ди безнең халык... Мәсьәләнең икенче ягы да бар: белем — кыйммәтле капитал ул һәм, көчемсез милектән аермалы буларак, ул һәрвакыт үзең белән, кусалар да, утырып калмый...

Милләтнең табигатенә, холкына аның үткәне, тарихы нык тәэсир итә. Читтә газап чиккәндә, яһүдиләр гел яхшы тормышка өмет иткән, авыр шартларны үзгәртергә тырышкан. Дөньяны үзгәртеп кору теләге аларның канына сеңгән. Франциядә яисә Рәсәйдә булып узган революцияләрдә еврей элементы көчле. Демократия өчен көрәшүчеләрнең алдынгы сафларында алар булыр. Бу элек тә шулай иде, хәзер дә. Хөкем сөрүчеләр, киресенчә, тотрыклыкка омтыла һәм яһүдиләрне күрә алмый...

Башкаларга ошамаган тагын бер сыйфатлары бар — кайда гына яшәсәләр дә, алар үзенчә яшиләр, үз телләрен, гореф-гадәтләрен саклыйлар. Рәсәйдә, мәсәлән, урыс булмаган барлык халыклар җайлы гына урыс культурасына интеграцияләнә, ягъни бу мохитта эреп, аерым милләт буларак юкка чыгып бара, ә болар бирешми. Рәсәйдә мондый үҗәтлек кичерелми. Олы мәртәбәләргә ирешкән берсе үзен еврей дип әйтсә, соңрак нык үкенә. Гусинский еврей конгрессы башлыгы иде, качып котылды. Березовский да ялгыш кына: “Мин яһүди”, дип ычкындырды бугай һәм шулай ук качарга мәҗбүр булды. Башкалар сабак алды: һәрвакыт уяу булырга, йомшап китмәскә. Менә шулай ул, шартлар характер тәрбияли...

*2004*

# КЕШЕ КҮПМЕ ЯШИ?

Бер кеше соң гына өйләнә. Тормыш арбасы кырыкны узып, иллегә тәгәрәгәндә генә моның баласы туа. Бар теләге баланы үстереп, аякка бастыру була. Иң авыр чакларда да ул бирешми, үз-үзенә: “Мин яшәргә тиеш!” — ди. Гел хәрәкәттә була, ходайдан да үзенә гомер сорый, саулык сорый. Ул кеше олы максатына ирешә һәм сиксәнгә кадәр яши. Аны баласы җирли, яшьтәшләре, дус-ишләре инде күптән зиратка килеп яткан була...

Ник бездә ирләр 50-60 яшендә кырыла? Чөнки ир-атлар 20-25ләрдә гаилә кора, гадәттә бер бала үстерә, аны кеше итеп, өйләндереп, аерым фатирга чакыра. Менә шулай: 50 яшендә тормышның олы максаты инде үтәлгән була, тагын яшәүнең мәгънәсе калмый. Җәмгыять тә андыйлар турында: “Ашын ашаган, яшен яшәгән”, — дип, теге дөньяга юл күрсәтә...

Элек ник озак яшәгәннәр? Яшәү шартлары авыррак та булган, әмма бабаларыбыз тормышның ямен-мәгънәсен җуймаган, чөнки мәсәлән, байлар алтмышта әле яңа гаилә генә корган — өченче яисә дүртенче хатын итеп, яшь кыз алып кайткан. Башкалар да нәүмиз булмаган, улларын башлы-күзле итеп, янында калдырган. Яшьләр тырышып эшләгән, олылар исә оныкларын тәбиялләгән. Менә нидә хикмәт — әби-бабай кирәк булган, барысы да, олысы-кечесе дә, бер тормыш казанында кайнаган. Бүгенге шәһәр исә миһербансыз, шәфкатьсез, анда беркем дә беркемгә дә кирәкми. Халык күп, әмма кеше бер-берсен белми, туганлык юк, якынлык юк. Шәһәрләшүнең төп бәласы да буыннарны аерудадыр ул. Гаҗәп хәл — бала үстер дә, оныкларыңны атнага бер тапкыр күр! Балалар үсә дә, ата-ананы ташлап, чыгып китә. Имеш, үзләренчә, теләгәнчә яшәсеннәр... Алар яшәр, картларга нишләргә? Тормыш программасы үтәлгән булып санала, аң тәнгә үлем әмере җибәрә...

Озын гомернең төп сере гади — ул озын гомергә ихтыяҗ булырга тиеш. Мин Грузиядә ял иткән идем. Анда халык бай яши. Гадәттә ике-өч катлы йортлар. Ул йортта әбиләр

дә, бәбиләр дә бар, бөтен бер нәсел яши. Һәркем үз урынында, үз эше белән мәшгуль. Ничек инде бездә шәһәр яшьләре кансыз булмасын, аларның янында чын-чынлап тәрбияләргә әби-бабай юк ки. Бүгенге шәһәр халыкның яшәү рәвешен үзгәртеп, нәсел җепләрен өзеп, җәмгыятьне тарката...

Кеше күпме яши? Ихтыяҗына күрә үз-үзенә нинди күрсәтмә бирсә, нинди гомерне — озынмы, кыскамы — максат итеп куйса, шуның кадәр яши. Галимнәр кеше кимендә 120 ел яшәргә тиеш ди, ә инде бик теләсә, хәтта 250-300 ел яшәргә дә мөмкин икән...

*2004*

## ХАКЫЙКАТЬ — ТУГАН ҖИРЕБЕЗДӘ

Май ае башының ямьле көннәрендә туган авылыма кайткан идем. Рәхәт, күңелле вакыт. Саимә апаларда чәй эчеп утырабыз. Әмма чәй тәмсез, тозлы кебек.

— Су начар авылда, — ди тугани апа. Үземнең беркатлылыгым белән:

— Ник чишмәдән китермисез? — дим.

— Караучы булмагач, чишмәләр күптән бетте инде, — диләр миңа. — Бездән иген генә сорыйлар, ит-сөтебезне алалар. Нинди су эчәсез, дип сораучы юк...

Гаҗәп хәл. Авылыбыз Лашчы елгасының нәкъ башында урнашкан. Әлбәттә, елга үзәне сусыз булмый, тирә-якта дистәләгән су чыганагы булырга тиеш. Димәк ки, чишмәләрне чистартып, төзекләндереп торучы гына юк. Әлмәт якларындагы чишмәләр исемә төште. Андагы җитәкчеләр тырышлыгы белән чишмәләр культура үзәге дәрәҗәсенә күтәрелгән — ял итәр өчен зур корылмалар төзелгән, сынлы сәнгать әсәрләре белән бизәлгән, чәчәкләр утыртылган...

Түзмәдем, икенче көн иртән елга буена чишмә ачарга киттем. Авылыбыз мулласы Зариф абый Хәсәнов очрады. Нишләп йөрүемне аңа да аңлаттым. «Изге ният белән йөрисең икән, улым», — ди бу. Зариф абый да чишмә булмауга, авыл халкының торбадан килгән тәмсез сары су белән ин-

тегүенә зарланды. Кырык эшен ташлап, миңа кушылды, бергәләп текә ярның төбенә төштек. Бихисап җирдән су саркый, үлән арасыннан сизелер-сизелмәс кенә булып үз ишләре белән берләшүгә юл ала. Кызык нәрсә икән ул чишмә ачу — булды, таптым дисең, казыйсың, күзәтә башлыйсың һәм казылган чокырга суның астан түгел, ә кайдандыр өстән, тирә-яктан килүен күрәсең. Башка җирдән казыйбыз, әмма су тамырын һич кенә таба алмыйбыз. Мәчет янындагы туган нигеземнең бакча башында да эзләп карыйбыз. Шул ук нәтиҗә. Күрәм, Зариф абый арды. Аның яше дә бар, олы кеше бит...

— Булмады, кайтыйк әйдә, Фирдүс, — ди бу. Мин ризалашам һәм китәр алдыннан калкулык төбеннән тагын ике-өч көрәк туфрак алам. Күзәтеп торам — чокырга су агып төшми, астан килә. Шатланып эти ягыннан туганыбыз булган абзыйны чакырам. Зариф абыйның да күңеле күтәрелде. Арганлыгы онытылып, бергәләшеп чишмә ачабыз. Кечерәк бура ясадык, өстен каплап, улак җайлаштырдык. Янына челтерәп аккан шифалы суны алырга чиләк куйдык.

—Кояш нык кыздыра башлагач, кайтырга чыктык. Авылыбызның мескен хәле күңелемне әрнетүен абыйга аңлатам.

— Беләсеңме, Фирдүс, кайчандыр Лашчыбашы зур һәм бай авыл булган, ул урман эчендә утырган, — ди туганым.

— Бу бик кызык, — дим мин. — Чөнки бүгенге көндә авыл шәрә утыра, сирәк-мирәк кенә агач очрый. Яшеллек юк диярлек. Болыннар, әрәмәлекләр сөрелгән, авыл тирәсендә ат аунарлык та тыныч җир калмаган — һәр квадрат метр туймас дәүләткә ашлык бирергә тиеш...

— Мин авылның тарихын яздым бит, — диде Зариф абый һәм, язмасын укып, кирәк булса төзәтеп, китап рәвешендә чыгарырга ярдәм итүемне сорады.

Китап чыгару җиңел эш түгел. Кулъязманы эшкәртү шактый күп вакытымны алды. Әмма бу эшне башкаруны мин шушы җирдә яшәп вафат булган барча ата-бабаларымның рухлары алдындагы бурычым дип санадым. Без аларны, алар сөйләгәннәрне онытмаска тиеш. Ата-бабаларыбыз-



ның сүзләрендә чын хакыйкать. Чит идеологияләргә, чит политикларга ышанып халкыбыз бүгенге хәленә килеп җитте. Карл Маркс һәм Фридрих Энгельс идеяләре шәп булгач, нигә соң алман халкы үзе аларны тормышка ашырырга ашыкмады? Узган гасыр башында тарих татар халкына бәхетле тормыш төзү форсаты бирде. Мәсәлән, финнар, поляклар бу форсаттан файдаланды. Беркатлы татар халкының зыялылары, әйдәп баручы асыл уллары исә Ленин һәм аның тирәсендәгеләрнең демагогиясенә ышанды һәм... һәлак булды. Беренчеләрдән булып Мирсәет Солтангалиев юк ителде...

Мәрхүм әбием Баһаветдин кызы Миңлехәләс революциягә кадәр бик рәхәт яшәдек, дип сөйли иде. Авылда берничә кибет эшләвен, аларда теләгән һәрнәрсә булуын, хәтта төсле чытыр кәгазьгә төрелгән әфлисуннар сатылуын әбиемнән ишетеп беләм. Саф сулы күлләргә, куе урманнарга бай булган Лашчыбашы. Халкы да, үзенә булгач, тырышып эшләгән, мул тормышта яшәгән. Социалистик пропаганда исә безгә киресен тукыды. Күпләр аңа ышанды, авыл халкының коллар хәлендә яшәвен аңламады. Инде күп еллар үткәч кенә әбиләребезнең хаклы булуларын төшендек. Димәк ки, хакыйкатьне Мәскәүдән яисә Лондон-Парижлардан эзләргә кирәкми. Хакыйкать әби-бабайларыбызның телендә, биредә — туган җиребездә.

Оста телле чит-ятларның барлык уй-ниятләре — безне алдау, байлыкларыбызны талау, безнең сыртыбызда яшәү... Гасырлар буе сыналган яшәү рәвешен җимереп, авылдашларыбыз 1930 нчы елларда колхоз төзи. Имеш, банклар басып, Кремльгә кереп утырган Сталин Лашчыбашының Әхмәтләрен, Вәлиләрен кайгырта. Юк шул. Аңа фәкать авыл халкының җелеген суырырга инструмент кирәк була... Нәтиҗәдә, игене, ите, сөте — җитештергән һәрнәрсәсе читкә китеп тора. Үзе исә ач яши. Колхоз рәисе Гайсин Борһан Гайса улы моңа түзми, колхозчыларга бераз икмәк бирә. Шуның өчен коммунистлар аны җәзалап үтерә... Җитәр, балаларча беркатлы булмыйк, читләргә табынмыйк. Туган җиребезне, үз халкыбызны олылыйк. Борһан абый Гайсин

кебеклəрнең исемнəрен мəңгелəштерик. Авылларыбызны торгызыйк, андый кешелəргə һəйкəллəр куйыйк.

Бүген дə социализм чорын сагынучылар күп. Аларга иярмик. Ул елларда безнең ата-аналарыбыз сыртында яшəүчелəр күп иде. Газиз җиребезнең җелеген — нефтен суырып, шуны сатып яшəде ул СССР дигəн дəүлəт. Татарстанның җиңел чыккан нефте бетүгə үк челпəрəмə килде...

Өметсез шайтан, ди. Яңа экономик шартларда яшəргə сəлəтсез булуын күрсəткəн колхозлар, һичшиксез, бетəр. Халык үз тормышына үзе хуҗа булыр, бəхетле булыр. Безнең халыкка гына нужа күрү димəгəндер, ул да бəхеткə лаектыр. Дөньяга үз карашыбызны, үзебезнең яшəү рəвешен, йолаларыбызны кайтарсак, килер ул якты көн.

2003

# ЭЧТӘЛЕК

Милләтпәрвар Фирдүс. *Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гәрәй РӘХИМ мәкаләсе*........................................................ 6
Гыйбрәт булсын *(сүз башы)* ........................................ 9
Татар теле укытучысы ............................................ 10
Евразия киңлекләрендә............................................ 10
Милләтне бүлмәгез!................................................. 15
Татарлар без, татарлар! .......................................... 16
Шәрыкка борылсак — ялгышмабыз.......................... 19
Казан хатыннары.................................................... 21
Һәлакәт ................................................................ 24
Хуҗа Насретдин кемнеке?....................................... 25
“Телдә, фикердә, эштә берлек”................................ 27
Мәчетләр нигә буш?................................................ 38
Зәлидә уены ......................................................... 40
Төрек татарга ярдәм итәрме? ................................. 42
Казанны яуласак — яшибез, юкса — бетәбез! ........... 48
Хак вә нахак ......................................................... 54
Моя Америка не боялась! ........................................ 57
Өйләнү *(татар малайларына ачык хат)* .................. 58
Айның кояш белән көрәше ...................................... 64
Алфавит турында ................................................... 66
Өч сум ................................................................. 67
Сак булыгыз! ........................................................ 68
Яһүдиләрне ник яратмыйлар? ................................. 71
Кеше күпме яши? ................................................... 73
Хакыйкать — туган җиребездә................................. 74

**Литературно-художественное издание**

**Фаткелисламов Фирдус Нурисламович**

**СВЯТЫЕ МЫСЛИ**
(на татарском языке)

Firdevs Fathelislam
KUTSAL DUSUNCELER
(Tatarça)

Редакторы *Гәрәй Рәхим*
Оригинал-макетны ясады *Азат Яшәр*

Оригинал-макеттан басыла. Форматы 60x841/16. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 4,80. Нәшер-хисап табагы 4,95.
Тиражы 1000 данә. Заказ

«Матбугат йорты» нәшрияты. 420111, Казан шәһәре,
Бауман ур., 19